ЯРАМЫЙ КИЧЕРЕРГӘ

Россиядә үлем җәзасын кире кайтару турында сөйләшәләр. Ни булыш бетәр?

> 5

ТЕЛДӘН ТӨШМИ

Мәскәү өлкәсендә булган теракттан соң тынычлыкны каян эзләргә?

> 6

КАЯ ТҮГӘРГӘ?

Тирескә бәйле яңа законның нечкәлекләрен аңлатабыз

> 7

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 39 (29199) | Җомга | 29 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КЫЗЫК ТҮГЕЛ:

ТАТАРЧА ЮМОР ТУРЫНДА ҖИТДИ СӨЙЛӘШҮ

Уен-көлке, шаян контент яшьләр өчен туган телне өйрәнүгә этәргеч була аламы? Булсын өчен нишләргә? Татар юморы заманына туры киләме? «Ватаным Татарстан» редакциясе каршында оешкан «Туган тел» клубының чираттагы утырышында 1 апрель алдыннан әнә шул сорауларга җавап эзләдек.

> 18–19

Ишетми калмагыз

Татарстанда, кинәт җылытып, яңгыр күп яуган очракта, кар бик тиз эреп, 39 шәһәр-районда барлыгы 220 торак пунктны су басарга мөмкин. Республика вице-премьеры Рөстәм Нигъмәтуллин әйтүенчә, быел язгы ташуга бәйле фаразлар борчу тудыра. Февраль ахырына кар катламы биеклеге күпьеллык уртача күрсәткечләрдән күпкә зур иде. Шуңа күрә язгы ташу киеренкелек тудырырга мөмкин. Вице-премьер билгеләп үткәнчә, районнарга инде бүгеннән үк ташуга җиң сызганып әзер торырга, ә су баса башласа, гадәттән тыш хәл режимына күчәргә тәкъдим ителгән. Сүз уңаеннан, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстанны су басу янаган 47 төбәк исемлегенә керткән.

Быел республикада 9,5 меңнән артыграк урынга 11 яңа мәктәп төзеләчәк. Мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин әйтүенчә, 8 мәктәп, шулай ук Коек мәктәбендә (800 урынга), Казанның 2 нче гимназиясендә һәм Кукмараның 3 нче мәктәбендә өстәмә бина пәйда булачак.
Уку йортлары «Мәгариф» илкүләм проекты буенча Татарстан бюджеты хисабына төзеләчәк. Алар Казанның «Весна» комплексында, «М-14» микрорайоны, Родина урамында, Лаеш районы Усад, Биектау, Комлы Кавал, Биектау районының Чернышевка авылларында, шулай ук Чаллының 65 нче микрорайонында калкып чыгачак. Моннан тыш быел 44 мәктәп һәм 20 балалар бакчасы бинасын капиталь төзекләндерү күздә тотыла.

Татарстанда «Нелегальный мигрант» чарасы төгәлләнгән. Тикшерү кысасында полиция хезмәткәрләре миграция турында закон бозуның 938 очрагын ачыклаган. Суд 75 кешене илдән куып чыгару турында карар кабул иткән.
Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, закон бозуларның күпчелеге (495 очрак) мигрантларның илебездә яшәү тәртибен санга сукмавына бәйле. Чит дәүләтләрдән 55 кешегә илебезгә керү тыелган. Моннан тыш Россия паспортына ия булган өч кеше тәрле җинаятьләре өчен паспортыннан мәхрүм ителгән.

Татарстанда күпфатирлы йортларда урнашкан җәмәгать туклануы урыннарында хәмер сатуны чикләмәкчеләр. Мондый кафе-барларда кичке сәгать уннан иртәнге унга кадәр спиртлы эчемлекләр сатуны тыярга ниятлиләр. Бары тик рестораннарга гына кагылмаска мөмкин бу. Дәүләт алкоголь инспекциясе әзерләгән закон проекты – әлегә коррупциягә каршы экспертизада. Документка караганда, күпфатирлы йортларда гына түгел, шул тирәдә урнашкан җәмәгать туклануы урыннарындагы кафеларда да «яшел елан» сатуга чик куелуы бар.

Районнарда ни хәлләр?

Актаныш

2024 елда Актаныш, Аеш, Яңа Кадермәт авылларында яшәп, алтын, зөбәрҗәт, тимер туйларын каршылаган парларны Актаныш районы башлыгы Ленар Зарипов тәбрик итте. Бу истәлекле чараның кунаклары – 50 еллык гаилә тарихына ия Ләйсән һәм Мирзахәниф Кадыйровлар, Яңа Кадермәт авылыннан Алмазия белән Мөдәрис Низамовлар, Аеш авылыннан Флүсә һәм Рәфит Ситдиковлар, 55 ел уртак гомер кичерүче Рәфига белән Мөдәллиф Галимәрдановлар, 65 еллык гаилә тарихына ия Мөслимә һәм Рәзиф Нургалиевлар булды.
(«Актаныш»)

Кайбыч

Район халкы 103 яшьлек сугыш ветераны Зиннәтулла Заһидуллинны соңгы юлга озатты. Ул 1920 елның 15 августында Иске Чәчкаб авылында Сафиябану һәм Әүхәт Заһидуллиннар гаиләсендә туа. Авыл мәктәбен 1937 елда тәмамлый һәм 1938/1939 уку елында Казан техникумының технология факультетына укырга керә. Зиннәтулла Әүхәт улы өчен сугыш Казан каймасыннан башлана. Бу вакытта ул авыл советы рәисе булып эшли. Окоп казырга килүчеләрне каршы алып, өйләргә урнаштыруда башлап йөри. Зиннәтулла Заһидуллин фронтка 1942 елда китә. Ржевтан башлап, Курск дугасындагы сугышларда, Белгород, Харьков шәһәрләрен азат итүдә катнаша. 1944 елда яраланып, туган авылына әйләнеп кайта.
(«Кайбыч таңнары»)

Мамадыш

Ямаш авылында бер ел элек мәчет янып юкка чыккан иде. Хәзер яңасын төзиләр. Авыл халкы моның өчен акча җыйды. «Безгә территорияне әйләндереп аласы һәм төзекләндерәсе калды. Газ үткәрәсе дә бар», – дип сөйли Ямаш авылында имам вазыйфаларын 20 ел башкаручы Газинур Хаҗиев. Аның сүзләренчә, яңа мәчет төзү теләге авыл халкын берләштергән. Барлыгы 1,5 млн сумга якын акча җыелган, шул акчага төзелеш алып барыла, ләкин бу гына җитми. «Үз өлешен кертергә теләүчеләр өчен ярдәм күрсәтү мөмкинлеге бар», – ди Газинур Хаҗиев.
(«Татар-информ»)

Зәй

Казанда укучы кызлар һәм егетләр арасында «Ак калфак» VII бөтенроссия бәйгесе тәмамланды. Финалда 7 егет һәм 8 кыз чыгыш ясады. Зәйнең Ринат Фәрдиев исемендәге татар гимназиясе IX сыйныф укучысы Әминә Хөснетдинова әлеге бәйгедә гран-прига лаек булды. Финалда кызлар кул эшләре, аш-суга осталыкта, спорт төрләре, татар биюе, вальс буенча да көч сынашкан.
(«Зәй офыклары»)

Рәис көндәлеге

ТУГАНЛЫК ҖЕБЕ

Татарстан белән Үзбәкстан арасын якынайту өчен күпер саласы юк. Ике дәүләтне күптәннән дуслык, хезмәттәшлек һәм туганлык җепләре бәйли. Әле күптән түгел генә Казан Үзбәкстан җитәкчеләрен үзендә кабул иткән булса, кунак ашы – кара каршы дигәндәй, безнекеләр дә озак көттермәде. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре белән Үзбәкстанда булды.

tatarstan.ru

Эш сәфәренең тәүге көне очрашуларга бай булды. Термизда Татарстан Рәисен «Айритом» ирекле сәүдә зонасына алып керделәр. 260 мең кв. метр мәйданны биләгән территориядә 3 меңләп кибет, склад, логистика үзәге урнашкан. Рөстәм Миңнехановка ирекле сәүдә зонасының өстенлекләре турында сөйләделәр.

Моннан тыш эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов яшелчә, җиләк-җимеш үстерү, келәм туку эшчәнлеге белән дә танышты.

Соңрак Сорхандәрья өлкәсе хакиме Олугбәк Косимов белән очрашып, хезмәттәшлек итү юнәлешләре турында сөйләштеләр.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Татарстан инвестицияләр өчен һәрвакыт ачык. Очрашуда Татарстан җитештерүчеләренең продукциясен Үзбәкстанга китерү һәм «Айритом» ирекле сәүдә зонасы мөмкинлекләреннән файдалану мәсьәләсе дә күтәрелде. Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча якын арада базарны өйрәнү өчен предприятиеләр делегациясе Үзбәкстанга киләчәк.

ТАТАРСТАН БЕЛӘН ҮЗБӘКСТАН АРАСЫНДАГЫ ТОВАР ӘЙЛӘНЕШЕ – САННАРДА

2022 ел – үсеш + 50%
290 млн доллар

2023 ел – үсеш + 27%
370 млн доллар

Үзбәкстанда КАМАЗ, «Химград», «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «Мастер» индустриаль паркы, «Эйдос», Казан федераль университеты филиалы эшли. Хезмәттәшлекне арттырып, товар әйләнешен якынча 1,1 млрд доллар күләменә чыгарырга кирәклеген җитәкчелек бер генә тапкыр билгеләп үтмәде.

Фикер

Камол БАБОХОНОВ,
Татарстан үзбәкләре мәдәни автономиясенең яшьләр бүлеге җитәкчесе:

– Ике республика бер-берсе өчен чит түгел. Без – тугандаш төбәкләр. Татарстан белән Үзбәкстан электән үк бер-берсе белән бәйләнештә. Милли традицияләр, мәдәни кыйммәтләр, сәүдә юлы дисеңме. Ике якның да бер-берсенә тәкъдим итәрдәй нәрсәләре, перспектив юнәлешләре күп. Татарстан да, Үзбәкстан да – икътисадый яктан караганда актив үсештә булган төбәкләр.

tatarstan.ru

Премьер-министр Алексей Песошин Казан Кремлендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырды. «Нәкъ менә сезнең талантыгыз, тырышлыгыгыз һәм ныклыгыгыз нәтиҗәсендә безнең республиканың көче арта, ул чәчәк ата. Сезгә бәхет, сәламәтлек, иминлек һәм киләсе көнгә ышаныч телим!» – диде Алексей Песошин тантанада. Барлыгы 49 кешегә дәүләт бүләкләре тапшырдылар. Алар арасында Казанның Совет районындагы 181 нче мәктәпнең математика укытучысы Фидария Мирзаян кызы Айзатуллова да бар. Хәзер ул «Татарстанның атказанган укытучысы» исеменә ия.

САЙЛАП АЛАЧАКЛАР

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге праймеризда катнашуга гаризалар кабул итә башлады. Анда җиңүчеләр сентябрьдә узачак сайлауда Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат була алачак.

Алдан тавыш бирүгә документларны беренчеләрдән булып «Яңа Гасыр» каналы генераль директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Илшат Әминов белән Питрәч районының Шигали авыл җирлеге депутаты, Россия Герое Дамир Исламовның апасы Динара Алтынова тапшырды.

Илшат Әминов фикеренчә, Татарстан Дәүләт Советы депутаты булу – үзенчәлекле миссия ул.

– Беренчедән, без – илнең иң зур тизлектә үсүче алдынгы төбәкләренең берсе. Икенчедән, Татарстан Дәүләт Советы – Россиядә федерализм үсеше, безнең илдә яшәүче халыкларның теле һәм мәдәнияте саклану гаранты. Мин бу кыйммәтләрне алга таба да сакларга әзер. Соңгы сүзне сайлаучыларыбыз әйтәчәк, билгеле, – дип сөйләде ул журналистларга.

Динара Алтынова исә үзенең төп бурычын республика халкы тормышын яхшырак, уңайлырак итүдә күрә.

– Миңа калса, Татарстанның бурычы – Россиянең үрнәк төбәгенә әверелү. Безгә охшарга тырышсыннар. Республика үсәргә, инновация тармагында алдынгы булырга тиеш. Соңгы вакыйгалардан соң шәһәребезнең куркынычсыз булуын да телим. Бүген бу аеруча мөһим. Балаларыбыз, гаиләбез, якыннарыбыз үзләрен якланган итеп сизәргә тиеш, – диде Динара Алтынова.

Исегезгә төшерәбез: 8 сентябрь көнне җиденче чакырылыш Татарстан Дәүләт Советына депутатлар сайланачак. Сайлауга алдан тавыш бирү 26 майга кадәр дәвам итә. 27 майда алдан тавыш бирүгә нәтиҗә ясалачак.

КАРАП ЙӨРИК!

ТАТАРСТАНДА ЮЛ ҺӘЛАКӘТЛӘРЕ САНЫ КИМИ, КОРБАННАР АРТА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстанның Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов журналистларга куркыныч саннарның кайдан килеп чыкканын аңлатты.

Корбаннар турында

Быел 85 көндә (Рөстәм Гарипов 23 мартка булган мәгълүматларны җиткерде. – **Ред.**) республикада 549 юл фаҗигасе теркәлгән. Аларда 63 кешенең гомере өзелгән. Корбаннар узган елгыдан 16га күбрәк. Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы сүзләренә караганда, 48 кеше машиналар бәрелешү, тагын 15е тапталу аркасында һәлак булган.

– Каршы як полосага чыгу аркасында килеп чыккан аварияләрдә 29 кешенең гомере өзелгән. Шуларның 28е – машиналарны узу рөхсәт ителгән урында. Кызганыч, машина йөртүче еш кына үз-үзенә артык ышанган була. Каршы як полосага чыкканда, юлның бушмы-юкмы икәнен дә тикшереп тормый, машинасының көчен, үз полосасына кайтып өлгерәчәкме-юкмы икәнлеген дә чамалап бетерми ул, – дип сөйләде идарә башлыгы.

Җәяүлеләр турында

Киемдә яктылык кайтаргыч булсын! Рөстәм Гарипов җәяүлеләр катнашындагы юл һәлакәтләрен киметүнең бер юлын әнә шунда күрә. Ник дигәндә, мондый фаҗигаләр, гадәттә, караңгы вакытта килеп чыга. Киемгә яктырткыч тагу мәҗбүри таләп буларак кертелгән илләрдә юл фаҗигасендә гомерләре өзелгән җәяүлеләр саны 70 процентка кимегән. «Яктылык кайтаргычлар балалар киемендә дә, өлкәннәрнекендә дә булырга тиеш. Зебрага аяк басар алдыннан башта борылып карыйк: машина йөртүче сезгә юл бирергә җыенамы-юкмы?» – дип искәртте баш инспектор.

Иминлек каешы турында

Машинага утыруга иң беренче эш итеп иминлек каешын эләктерергә кирәк! Рөстәм Гарипов журналистлар белән очрашкан саен әйткән бу сүзне янә кабатлады. Быел каеш эләктермәгән булулары аркасында дүрт кешенең гомере өзелгән. «Авыл буйлап йөрисезме сез, шәһәрдәме, трассадан барасызмы – мөһим түгел. Туктап торган машинага икенче бер машина килеп чәкелсә, артта утырган кеше ян тәрәзәгә бәрелә. Каешы эләктерелгән булса, мондый хәл килеп чыкмаячак», – дип ачыклык кертте Рөстәм Гарипов.

Балалар турында

Былтыр республика юлларында 17 баланың гомере өзелгән. Быелгы өч ай саннарына карасак, балалар катнашында килеп чыккан аварияләр саны арткан-лыгын күрәбез. Рөстәм Гарипов: «Машинада барганда, бала махсус утыргычта утырырга, иминлек каешы эләктерелгән булырга тиеш. Бакчага, мәктәпкә барыр алдыннан юл кагыйдәләре турында балаларның исенә төшерергә дә онытмасак иде», – диде.

Тәҗрибәсез машина йөртүчеләр турында

1 апрельдә машина йөртү таныклыгы алу өчен имтихан тапшыру тәртибе үзгәрә. Имтиханны өч тапкыр тапшыра алмаган кеше дүртенче сынауга ярты ел узгач кына керә алачак. Тәҗрибәсе ике елдан кимрәк булган йөртүчеләр гаебе белән быел 22 авария килеп чыккан. Рөстәм Гарипов күпләрнең имтихан тапшырырга әзерлексез килүен, теория өлешен генә түгел, практиканы да беренче тапкырдан тапшыра алмауларын әйтте.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Юллардагы вазгыять – саннарда

	01.01.24 – 25.03.24	Узган ел белән чагыштырганда
аварияләр	549	–43
үлүчеләр	63	+16
имгәнүчеләр	690	–62

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Сабый

– Ярамый! – дип тыярга тырышам, тик ул уйлап та бирми, мин тагын бер кабатлыйм. Ә ул икенче җиргә үрелә, анысы да ярый торган түгел.

Гел ярамаган нәрсәләрне генә карап тора. Бу кечкенә сабыйларның күзләре бүтән төрлерәк күрәме, башлары үзенчә эшлиме икән, кайда нәрсә аркылы ята – шуңа ябышалар, нәрсәгә тияргә кирәкми – шунда үреләләр. Бер мизгелгә дә күздән яздырмыйча, артларыннан каравыллап кына йөрергә туры килә.

– Һай! – дип дәртләнеп чаптырып китә ул һәм газ плитәсендә кайнап утырган кәстрүлгә үрелергә итә. Мин йөгереп килеп кулыннан тотам. Ә ул тыңламый, кулын тартып алырга итә, булдыра алмагач, икенче кулын суза. Аңлап торам инде, дөнья белән танышасы килә аның. Барысын да тотып карыйсы килә. Үзе теләгәнчә яшисе килә. Мин бәласеннән баш-аяк дип читкәрәк алып китәм, ул икенче мизгелдә стена янына килеп, обойның тырнак очы кадәр генә кайтарылып торган җирен тарткалый башлый.

– Я-ра-мый, – дим, аны читкәрәк алып. – Уенчыкларың да җитәрлек бит инде, уйна шулар белән.

Тик ул аларга борылып та карамый, ваннага йөгереп китә һәм кранны ачып җибәрә. Су чәчри, ә ул, шатланып, читкә сикерә. Аннан соң сөлге алып, юешләнгән киемнәрен сөртә дә, аны идәнгә ыргытып, ары чаба.

– Урынына куярга кирәк.

Ул кире борылып килә. Сөлгегә иелә. Һәм бик эшлекле кыяфәт белән идәнне ышкый башлый. Идән юганны күргәне бар, бу да шулай итә. Аннан соң үзенең зурлар эшен булдыра алуына сөенеп, сөлгене мунчалалар тора торган җиргә илтеп ташлый да кран янына килеп кулларын юа. Ул кулын юганда тирә-яктагы бөтен нәрсә юыла...

Күздән яздырырга ярамый. Аз гына ирек куйсаң, ул әллә нәрсәләр китереп чыгарырга мөмкин. Үзен дә имгәтергә, бүтән нәрсәләргә дә зарар салырга. Әле ул газ плитәсен борып китәргә дә, розеткага берәр нәрсә илтеп тыгарга да күп сорамас. Шуңа гел күзәтеп, гел тыеп торырга туры килә.

– Ярамый! – Кечкенә балалы йортта иң еш кабатлана торган сүз шушы бугай.

Әле менә әнисе белән урамда йөреп керергә чыгып киттеләр дә бераз тынычланып калдым. Сабыйларга ачуланып булмый. Мин үзем дә кечкенә вакытта бик тынгысыз булганмын дип сөйлиләр. Кемгә охшарга тиеш шулай булгач?

Тынып калган арада эшләрне бераз караштырырга кирәк. Язарга. Мин компьютер алдына килеп утырдым да темаларны барларга тотындым. Иң җанны әрнеткәннәннән башларга кирәк... Тик шундук үземне кайнап торган кәстрүлгә үрелгән бала шикеллерәк тойдым. Ярамый! Үрелә белми үрелсәң, кулың гына түгел, авызың да... әллә нәрсәләреңә пешәргә мөмкин, кыскасы. Ә күңел, сабый бала сыман, әле ул темага, әле монысына үрелә... Күңелнең күзе бүтән төрлерәк микән, ул гел иң кирәкмәгән нәрсәләрне күрә, гел шунда үрелә, әллә нинди ярамаган әйберләрне казып чыгара... Ә мин тыям... Тыярга кирәк. Ярамый. Ярамау ул куркудан гына түгел, җаваплылык тойгысыннан да хасил була – кайбер сүзләрне әйтергә иртәрәк, кайсылары авыр ишетелергә мөмкин. Күп бит инде...

Без никадәр генә зур үссәк тә, сабыйлыгыбыз беркая да китми икән. Ул бездә яши. Гел ярамаган гамәлләр кылырга атлыгып тора. Ә өлкәнлегебез шуны тыеп тота. Бала караган шикелле яшибез инде шулай.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ ҺӘМ ТОРМЫШ ДӘРӘҖӘСЕ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Февраль ахырында Росстат Россиядә 2023 елда хезмәт хакы үсеше турында рәсми нәтиҗәләр игълан итте. Үткән ел уртача хезмәт хакы 2022 ел күрсәткечен 14 процентка узган. Иң мөһиме: хезмәткә түләүнең номиналь күләме генә түгел, реаль күләме дә үскән, ягъни инфляция күрсәткечләрен алып ташлаганнан соң да хезмәт хакы 8,5 процентка арткан. Кемнең хезмәт хакы артмады, тынычланыгыз: сүз уртача үсеш турында бара. Кемнәрдер 100 процентка күбрәк ала башлагандыр, кемнәрдер кимрәк тә алып эшли башлагандыр, мөгаен.

Мәгълүматның башка төрләре дә бар. «Врачи РФ» дигән берләшмә, әйтик, сораштыру үткәргән: табибларның 57,5 проценты хезмәт хакының ашау-эчүгә, торакка һәм дәвалануга булган ихтыяҗларын капларга җитмәвен әйтәләр икән. Ак халатлыларның өчтән бере – 20–40 мең сум хезмәт хакына, тагын өчтән бере 40–60 мең сумга эшләүләрен яшермәгән. Росстат исә, табибларның уртача хезмәт хакы үткән елның беренче яртысында ук 105 мең сум иде, дип әйтә. Без статистика идарәсе мәгълүматларына шик белдермибез. Бюджеттагыларга бик аз хезмәт хакы түләгән төбәкләр бар, шактый югарыны гарантияләгәннәре дә җитәрлек. Сораштыруда барлык табиблар катнашмый, анысын да исәпкә алырга кирәк. Әйтик, 150 мең сумга эшләгән табиблар арасында гына сораштыру үткәрсәк, бөтенләй башка нәтиҗәләр күрәчәкбез.

Шушы урында автор аз гына лирик чигенеш ясый. Хезмәт хакы тормыш дәрәҗәсен билгеләүче бердәнбер фактор түгел, дип әйтә. Мәҗдиевне аз гына үзгәртеп, бәхетсез олигархлар бар, бәхетле көтүчеләр дә була ала, дигән фикерне алга этә. Бу фикерендә ул Альберт Эйнштейнга таяна. 1922 елда Токиода лекцияләр укып йөргәндә, аның кунакханә номерына телеграмма китерәләр. Гадәттә мондый очракларда йомышчыга чәйлек бирәләр. Әмма Эйнштейнның әллә вак акчасы булмаган, әллә башка сәбәптәнме, ул чәйлек акча урынына кунакханә бланкына берничә сүз язып бирә. 2017 елда бу бланк аукционда 1,56 миллион долларга сатыла. Ләкин аның кыйммәте бәясендә түгел, эчтәлегендә. Бөек галимнең: «Тыныч һәм тыйнак тормыш тукталусыз уңыш артыннан куып, даими борчылып яшәүгә караганда күбрәк бәхет китерә», – дигән сүзләре күпләргә мәгълүм, ләкин бик азлар гына файдалана торган хакыйкатьне язган. Хезмәт хаклары Росстат игълан иткән уртача хезмәт хакыннан берничә тапкыр кечерәк (андыйлар зур күпчелек дип беләм) икән, Эйнштейн формуласын файдаланыгыз һәм бәхетле яшәгез.

Автор шулай да тормышның матди ягын уртача хезмәт хакына салып үлчәп карарга ниятли. Чагыштыру өчен 2001 ел белән 2023 елны ала. 2001 елда илдә уртача хезмәт хакы – 3240 сум, АКШ акчасына күчергәч, 111 долларга тигез. Соңгы сан безнең ул чакта никадәр фәкыйрь яшәвебезне күрсәтә дә инде. Ул чакта яңа Россия автомобиленең уртача бәясе – 124 мең сум, ә яңа иномарканың уртача хакы 570 мең сумга тиң булган. Уртача хезмәт хакына Россия автомобиле алу өчен – 38 ай, ягъни өч елдан аз гына артык эшләү таләп ителгән. Яңа чит ил автомобиленә 14,5 ел тир түгү соралган.

«Интерфакс» 2023 елда уртача хезмәт хакы 73709 сум дигән сан китерә. Яңа автомобильләрнең уртача бәясе – 3,7 миллион сум. Көнбатышның популяр брендлары инде сатуда юк диярлек, арзанлы Кытай автомобильләре өстенлек итә, шуңа күрә уртача бәяләрне чагыштыру кыен. Уртача бәядәге яңа автомобиль алу өчен 50 айдан аз гына артык вакыт уртача хезмәт хакы җыеп барырга кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Уртача хезмәт хакына торак сатып алып карыйк. 2001 елда Россия буенча торакның квадрат метры, бик нык артып, уртача 9,1 мең сумга җиткән. Бер квадрат метр алу өчен, уртача хезмәт хакына 2,8 ай эшләргә кирәк булган. 2023 елның уртача квадрат метры – 122,815 мең сум (Казанда – 165 мең сум тирәсе). Казанда Россиянең уртача хезмәт хакын алып эшләсәң, квадрат метрга – 2,2 айлык хезмәт хакы, Татарстанның уртача хезмәт хакына тир түксәң (59500 сум), 2,77 айлык хезмәт хакы таләп ителә. 2001 елда без бик авыр тормыш кичердек: бәяләр югары, хезмәт хаклары түбән иде. 22 елдан соң тормыш бераз уңайланган, әмма күпкә түгел. Хезмәт хакларының артуы (реаль хезмәт хакы арта, дип белдерсәләр дә) тормышның матди ягын бик алай югары күтәрми.

Акчаны ничек тотуга бәйле рәвештә, 2023 елның югары хезмәт хакы 2001 елның түбән хезмәт хакыннан кечерәк тә булып чыга ала әле хәтта. Мәсәлән, 2001 елда уртача хезмәт хакын туплап, бер унция алтын алсаң (әйтик, НДС салымы түләтми торган илдән), 2023 елда аны сатсаң, якынча 77370 сум акча алачаксың. Ягъни алтында исәпләгәндә 22 ел элеккеге хезмәт хакы зуррак булып чыга. Кызык бит, әйеме? Бу җәһәттән караганда, бер дә алга китеш юк. Сум тагын бераз девальвацияләнеп, алтын тагын да кыйммәтләнсә, 2001 елгы эшләгәнең күпкә зуррак булачак. Ә менә уртача хезмәт хакын йомыркаларда үлчәсәк, 2023 елгы хезмәт хакы ота. Россиялеләр 2023 елда йомырка кыйммәтләнде дип үрсәләнделәр. Чынлыкта уртача хезмәт хакы коэффициентына куеп үлчәсәк, монннан 24 ел элек йомырка хәзергедән 4 тапкыр кыйммәтрәк йөргән. Икенче төрле әйткәндә, 2000 елгы уртача хезмәт хакына 2023 елгыга караганда 4 тапкыр азрак йомырка килгән.

Владимир Путин хезмәткә түләүнең минималь күләмен 2030 елга 35 мең сумга җиткерергә дигән бурыч куйды. Тормыш яхшырачак дигәнне аңлатмый бу сан. Бәлки, яхшырыр да, бәлки, киресенчә, матди кыенлыклар күрергә туры килер. Хезмәт хакы үсеше динамикасы буенча иң зур рекордлы чак – 1992–1993 еллар. 1993 елның гыйнварында Россиядә уртача хезмәт хакы 15300 сум иде, декабрьдә 141200 сумга җитте, үсеш темпы – 9,22 тапкыр. Ел башында россияле уртача 36,6 долларга эшләгән, декабрьдә 113,23 доллар алган. Беренче карашка хезмәт хакы долларда да үскән кебек, әмма бу бер генә нәрсәне аңлата: ике-өч ай элек эшләгәнең бүген инде берничә дә ярамый. Бөлдерә торган финанс сәясәте ул хезмәт хакының үсеш темпы.

Җитәкчегез түләгән хезмәт хакы аз булып тоелса, Эйнштейнның йөз ел элек язган киңәшен укыгыз. Күрәсез бит: доллар очсызлана. Сумнар чүпкә әйләнә, теге киңәшнең кыйммәте арта.

Әйтеп кенә бактым

Татар булсын, яме!

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Мине күп сөйләшүдә гаеплиләр. «Авызыңда сүз тормый, ир кешегә бер дә килешми», – диючеләр дә бар. Нишлим соң, Ходай шулай яраткандыр инде. Әти дә, әни дә бик ачык күңелле, кеше белән тиз аралашучан иде, әмма авызларыннан бер генә гайбәт сүз дә чыкмады. Мин дә кеше сөйләп йөрмим. Миңа «ябык китап» булган кеше күңелен укып карау һәм үземнең күңел капкаларын да киереп ачып кую кызык.

Яхшы сүздән берәүгә дә зыян килгәне юк әле. Һәм, ни гаҗәп, соңгы вакытларда яшьләргә тартыла башладым. Аларның нинди уйлар белән яшәгәнен беләсе килә. Юкса күбрәк чордашларым белән аралашырга тиеш кебек. Яшьтәшләр белән уртага салып сөйләшер сүзләр күбрәк була бит инде, шулай үткән яшьлектән башлыйсың да бүген нинди дарулар эчү белән тәмамлыйсың. Тик менә мондый сүзләрне күңел кабул итми башлады, яшәрәсе, егет чакларга кире кайтасы килә.

Редакция урнашкан бинаның беренче катында кофе сатучы яшь кызлар белән дә уртак уйлар, сөйләшәсе сүзләр юк кебек. Бу дөньяда мин – алардан өч тапкыр күбрәк яшәгән кеше, шулай да аерылып китәсе килми, чукынчык. Иртә таңнан шул тирәдә чуалганымны күреп, редакция кызлары: «Яшьләргә бик карый башладың әле, Риман абый, хатыныңа әйтми булмас», – дип төрттергәлиләр. Үзегезгә карагыз инде, фәрештәләрем минем.

Кофе белән сыйлаучы кызларның берсе Ирина исемле. Әле егерме яше дә тулмаган. Бер көнне гел авызы ачыла моның. «Че, Ириша, спать не дают, да?» – дигән булам.

– Нет, просто устаю, – ди. Ничек арымасын инде сабый, ике эштә эшли икән, үзенчә тормыш куа. Кияүгә чыккач, бөтенләй эшләмәскә исәбе. Балалар үстереп, ир тәрбияләп яшәр идем, ди бу. Тик менә үзенә ошаган егет очрата алмый икән әле. «Главное, чтоб был татарином. Может вы найдете?» – дип көлә.

Көлүен көлә дә, шаяртмый икән Ирина. Миңа татарларны ни өчен яратуы турында үзенчә дәлилләр китереп сөйләгән була. Мин аны бераз өркетергә телим. «Татарлар – консерватор, син бары тик ир сүзе белән генә яшәргә тиеш буласың, прощай, свобода! Ураза тотарга да туры килмәгәе, бездә ураза сезнең пост кебек түгел, кояш чыкканнан кояш батканчыга хәтле авызга бер тамчы ризык та каба алмыйсың. Әле мәчеткә дә йөрергә туры килмәгәе», – дип тезеп китәм. Ә Иринаның үз туксаны – туксан: «Главное – любовь, ради любви на все пойду. А татары – очень трудолюбивый, преданный, честный народ», – ди.

Үзе Алексеевск районыннан икән, авыл кызы. Авыл – шәһәр түгел инде ул, анда милли мохит тә башкача. Ирина да татарлар белән аралашып үскән, димәк, безнең иң күркәм гадәтләребезне үзенә сеңдерә барган дип уйладым.

Инде менә ничекләр генә итеп Иринага бер җүнле татар егете табарга икән дип баш ватып йөрим. Нәкъ менә җүнлесе белән таныштырасы килә, яшь кенә марҗа кызының татарга карата фикере, югары бәясе начар якка үзгәрерлек булмасын, дим.

Менә бит күп сөйләшүнең файдасы: Ирина, үзе дә уйламастан, милләтемә булган мәхәббәт, горурлык хисләремне тагын да арттырды. Спасибушки, Ирина! Ә мин, үз чиратымда, сине милләтнең бер асыл егете белән таныштырырга тырышырмын.

P.S. Бу язма газетада чыгар алдыннан бер сөенечле хәбәр ишеттем. Ирина бер татар егете белән очраша башлаган.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

СОҢГЫ ЧИК

РОССИЯДӘ ҮЛЕМ ҖӘЗАСЫН КАЙТАРУ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘЛӘР

Мәскәү өлкәсендә булган фаҗига кабат Россиядә үлем җәзасын кире кайтару турында бәхәс уятты. Моны телгә алу бөтенләй үк нигезсез дә түгел кебек. Кыргыйлык саналса да, бу хакта сүз куертуга кыргый очраклар этәрә түгелме соң?

tatmitropolia.ru

«Кайнар» сорау

Билгеле булганча, илдә үлем җәзасы бирү рөхсәт ителә, тик аны гамәлгә ашыруга мораторий (кичектерү хокукы) салынган. Үлем җәзасы билгеләнгән очракта да, нигездә, иректән гомерлеккә мәхрүм итү белән чикләнәләр. Гамәлдәге закон нигезендә, Россия Җинаятьләр кодексының биш маддәсе буенча (мәсәлән, геноцид, дәүләт яки җәмәгать эшлеклесенә һөҗүм һ.б.) кешене үлем җәзасына тартырга мөмкин.

Сүз уңаеннан, соңгы тапкыр Россиядә үлем җәзасы 1996 елда гамәлгә ашырылды: 11 малайны көчләгән һәм үтергән өчен Сергей Головкинны аттылар.

Җәмгыятьне ике төркемгә бүлә торган әлеге мәсьәләгә Мәскәү өлкәсендә булган фаҗига – «Крокус Сити Холл»дагы теракттан соң әйләнеп кайттылар. Гаепләнүчеләрне җәзаларга ярамый кичерергә. Өтерне кая куйсак, гаделрәк? Җинаятьчегә намус йөген сөйрәү, вөҗдан газабы үлемгә караганда кырысрак җәза булмасмы? Золым тагын да көчлерәк золым тудырмасмы?

Гадәттәгечә, үлем җәзасы дигәндә, Дәүләт Думасы депутатлары да активлаша. Кайсылары, коточкыч җинаять кылучыларга (әйтик, теракт, көчләү һ.б.) моннан да гаделрәк чара юк, дисә, кемнәрдер референдум оештырып, халык фикерен белешергә кирәк, ди. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин исә: «Конституциядә, җинаять законнарында берәү дә үлем җәзасын гамәлдән чыгармады. Мондый хөкем карарын чыгаруны кичектереп торучы Конституция суды карары бар. Шуңа күрә бернинди референдумнар да кирәкми, бу мәсьәләдә Конституция суды карары да җитә, – диде. – Әмма теләсә нинди карарны аек акыл белән кабул итәргә кирәк».

«Кайнар» сорауны сенатор Андрей Клишас та җавапсыз калдыра алмады. Аның фикеренчә, террорчыларны һәм педофилиядә гаепләнүчеләрне үлем җәзасына хөкем итү мөмкин түгел. Хәтта мораторий алынган очракта да.

– Конституция нигезендә үлем җәзасына присяжный утырышчылар катнашында узган суд эшеннән соң гына хөкем итәргә мөмкин. Ә гамәлдәге закон буенча террорчылык һәм педофилия маддәләренә кагылышлы эшләр алар катнашыннан башка гына уза, – дип аңлатты ул.

ПОЛИТОЛОГ СЕРГЕЙ МАРКОВНЫҢ ҮЛЕМ ҖӘЗАСЫН КАЙТАРУГА БӘЙЛЕ КАЙБЕР ФИКЕРЛӘРЕ

Каршы ✕	Каршы түгел ✓
Тикшерүче һәм судьяларның ялгышуы ихтимал. Ялгыш үлемгә хөкем ителгәннәр шактый.	Җәмгыятьтәгеләрнең күпчелеге үлем җәзасын кире кайтару яклы. Ә хакимият халык ихтыярын үтәргә тиеш.
Гомерлеккә хөкем итү – үлем җәзасына караганда күпкә дөресрәк җәза.	Үлем җәзасы кыргый җинаятьләргә карата кулланылырга тиеш. Бу золым кылучылардан зыян күрүчеләргә һәм аларның туганнарына карата гадел булачак.
Үтерүче яисә террорчы, гадәттә, акыл һәм әхлакый яктан сәламәт кеше түгел. Шуңа күрә алар үзләре дә – корбан.	Еш кына авыр җинаятьләр өчен утырып чыккан кешеләрне иреккә чыгаралар. Андый кешенең иректә йөрүе бер дә гадел түгел.
Статистикага күз салсаң, үлем җәзасы гына көч куллануга бәйле җинаятьләр санын киметми.	Үлем җәзасына кешелек иң соңгы чиккә җиткәч мөрәҗәгать итә. Ягъни җинаятьләр саны, үтерү очраклары артканда һәм шуларны туктату нияте белән.
Цивилизациянең үсеш күрсәткече –көч куллануны киметү, шул исәптән «үлем җәзасы» дигән төшенчәне юк итү дә.	Үлем җәзасы янавын белгән потенциаль җинаятьче тыелып калырга мөмкин.
Ил алга киткән саен, анда үлем җәзасы куллану ихтималы азрак.	
Диннәр дә: «Үтермә!» – ди.	
Үлем җәзасы үтерүләр санын арттырырга мөмкин. Шул исәптән гаиләдә көч куллануны да.	
Белемле һәм мәдәниятле кешеләр үлем җәзасына каршы. Һәм киресенчә.	

(телеграм-каналыннан)

Amnesty International оешмасының статистикасына күз салсаң, 2022 елда дөньяда 883 үлем җәзасы гамәлгә ашырылган.

Кирәкме, юкмы?

Адвокат, Юристларның милли ассоциациясе (НАЮР) президенты Руслан Нәгыев менә нинди фикердә:

– Үлем җәзасын кире кайтару өчен, хокук саклау һәм суд системасының эш сыйфаты искиткеч дәрәҗәдә булырга тиеш. Тик әлегә мондый эш тел-теш тидергесез рәвештә алып барыла дип әйтеп булмый. Моның берничә сәбәбе бар. Мәсәлән, кешегә җинаять җәзасы биргәндә артыгын кыланган өчен, гаепсезгә яисә законсыз дәлилләр нигезендә җәза биргән өчен, тикшерүчеләр һәм судларның үзләрен җаваплылыкка тарту системасы тиешенчә эшләнеп җитмәгән. Россиядә хөкем ителүчене аклау йөзеннән чыгарылган карарлар хөкем карарларының нибары 1 проценттан кимрәген тәшкил итә. Мондый күрсәткечкә ия булганда үлем җәзасын кайтарырга ярамый. Гаепсезләр җәзаланырга мөмкин чөнки. Суд хатасы белән кешене ирегеннән мәхрүм итү – бер мәсьәлә. Ә инде гомерен өзү – бөтенләй икенче…

Россия Адвокатлар федераль палатасы советы әгъзасы Виктор Буробин фикеренчә дә, бу – хисләргә бирелеп хәл ителә торган мәсьәлә түгел.

– Мондый җитди тетрәнү кичергән шартларда җәмгыятьне мәсьәләне күпчелек уйлаганча хәл итәргә чакыру дөрес түгел. Бу сорауга җавап хокук фәнендә ята. Җинаятьчелек күренешен җәмгыять һәм дәүләт контрольдә генә тота ала. Җәмгыять шуны аңларга тиеш: үлем җәзасын кайтару гына куркынычсызлыкны тәэмин итмәячәк. Киресенчә булмагае. Үлем җәзасының булуы җинаятьчелекне туктатмый, – ди ул. – Үлем җәзасын торгызу, һичшиксез, башка төр җәзаларны кырысландыру һәм аны башка җинаять төрләренә куллану мөмкинлеген киңәйтәчәк.

«Аны хәзер атачаклармы?»

1989 елның 11 апрелендә Чаллы шәһәрендә яшәүче 18 яшьлек Елена хәбәрсез югала. 45 нче комплекстагы өйдән чыга да кире кайтмый. Соңрак 17/01 йорт тирәсендә аның мәетен табалар. Кыз вәхшиләрчә көчләнгән!

Хокук сакчылары җинаятьтә шикле кешене тиз таба. Бу 34 яшьлек Михаил Васякин була.

...Михаил Еленаны ресторанга чакыра, күңелле кичәдән соң озата бара. Юллары ташландык урыннар аша үтә. Шушында ук Михаил кызга бәйләнә башлый, көчле һәм үтерә.

Әлеге коточкыч фаҗига халыкта зур ризасызлык тудыра. Гаепләнүчене күрсәтмә суд белән хөкем итүне һәм иң авыр җәза бирүне сорыйлар. Ачык суд эшендә катнашырга теләк белдерүчеләр саны 4 меңгә җитә. Вәхшиләрчә үтерелгән кызның әтисе Горбачевка һәм СССР прокуратурасына хатлар юллый...

Җәмәгатьчелек теләген исәпкә алып, Югары Суд ачык суд процессы булачагын игълан итә. Аны Гренада паркында стадионда оештыралар. Суд дүрт көнгә сузыла...

Хөкем карарын Илгиз Гыйләҗев чыгара. Бу көннәрне менә ничек искә ала ул: «Суд утырышында катнашучылар белән фикерләшү өчен, стадион уртасына «УАЗ»иклар куелган иде. Дүрт сәгать узгач, машинадан чыгып, карарны игълан иттек – гаепләнүчегә иң авыр җәза. Халык тынычланды, тарала башлады. Минем яныма бер әби килде дә: «Улым, ә аны хәзер үк атачаклармы?» – дип сорады» *(ачык чыганаклардан алынды)*.

Хөкем карары 1990 елның 29 ноябрендә гамәлгә ашырыла.

Илгиз ГЫЙЛӘҖЕВ,
Татарстан Югары Судының элеккеге рәисе:

– Чаллыда мин беренче тапкыр үлем җәзасына бәйле хөкем карары чыгардым. Ә барлыгы – дүрт мәртәбә... Мин, моның ни дәрәҗәдә кыен икәнен аңласам да, үлем җәзасы яклы. Җәза кылынган җинаятькә туры килергә тиеш. Бик куркыныч җинаятьләр бар, алар өчен, гафу итегез инде, җәзаның иң югары чарасы гына кала. Төрле җинаятьләр бар. Ә менә Чикатило кылган җинаятьләргә нинди мөнәсәбәттә булырга? 50–60ар мәет, үтерүләр, мыскыл итүләргә ничек карарга? Бу – гомерлеккә төрмәгә утыртуга тиңдәш җинаятьме? Мәрхәмәтсез маньяклар яисә балаларны үтерүчеләр очрагында аларны туры юлга бастыру, төзәтү турында түгел, ә үч алу турында гына сөйләргә мөмкин инде. Шул ук вакытта, мондый карар чыгарырга мөмкинлек бар икән, аннан файдаланырга кирәк.

(2019 елда Казан федераль университеты студентлары белән очрашуында әйткән сүзләре, интернеттагы ачык чыганаклардан алынды)

Сәяси сәгать

ВЛАДИМИР КУТИЛОВ:

«Куркыныч хәбәрләргә ияләшеп булмый»

Без әле кая барабыз? Дөньяданиләр бар? Бу сорауларга җавапны политтехнолог, «Теория Дарвина» агентлыгы генераль директоры Владимир КУТИЛОВ белән бергә эзлибез.

:: Владимир Путин «Россия – бары руслар өчен генә!» – дип кычкыручыларга карата фикерен белдерде. Президент әйтүенчә, мондый куркыныч фикерләр тормышка ашса, ил таркалачак. Ничек уйлыйсыз, Мәскәү өлкәсендәге куркыныч вакыйгадан соң мигрантларга карата мөнәсәбәт үзгәрерме?

– Миңа калса, бу мәсьәләдә зур үзгәрешләр була алмый. Берничә сәбәбе бар. Беренчедән, без – зур һәм күптөрле милләтләр яшәгән ил. Бу – безнең мәдәниятнең дә, традицион кыйммәтләрнең дә бер өлеше. Икенчедән, мигрантлар, миграция – икътисадның һәм демография сәясәтенең мөһим бер өлеше. Бездә генә түгел, Европа һәм АКШта да шундый вазгыять. Эшче көчләр җитми. Бер яктан, вазгыятьне кулдан ычкындырырга ярамый. Икенче яктан, эшкә дип килгән мигрантларсыз да булмый. Аннары бер нәрсәне онытмыйк: ул кешеләр арасында бездәге тормышка ияләшкән, җәмгыятьтә үз урынын тапкан, гражданлык алганнары да бик күп.

:: Әмма вазгыятьне какшатырга тырышучылар да бар.

– Беләсезме, милләтчелек идеясе бик гади һәм аны кешенең башына сеңдерү дә бик җиңел. Милли кыйммәтләрне сакларга тырышуның бернинди начар ягы да юк. Әлеге идеяләр куркыныч радикаль төсмер ала башлаганчы. Әнә шуңа күрә – җиңел генә сеңдереп һәм радикаль төсмер биреп булганга – мондый фикерләрне вазгыятьне какшату өчен кулланалар да инде. Безнең дошманнар да милли мәсьәлә һәм мигрантлар темасын Россиянең иң авырткан җире дип саный. Шул урынны ныграк авырттырырга телиләр. Соңгы арада Дагыстанда, Башкортстанда килеп чыккан вакыйгаларда без моны күрдек инде.

:: Соңгы арада Россиядә үлем җәзасын кире кайтару турында күп сөйләшәләр. Беренче тапкыр түгел. Әмма бу юлы исеме билгеле һәм сүзе үтә торган кешеләр дә читтә калмады. Ни дигән сүз бу: халыкның фикере белән уйнаумы, әллә, чыннан да, җинаятьчелеккә каршы көрәшме?

– Миңа калса, моны сезгә теләсә кайсы белгеч раслаячак, үлем җәзасы гамәлдә булу гына җинаятьләрне булдырмый калуга, аларның санын киметүгә йогынты ясый алмый, ясамый да. Бу – сәяси мәсьәлә. Шуңа күрә сәясәтчеләр бу хакта күп сөйли дә инде. Россия җәмгыятенең зур үзенчәлеге бар: бездә халык һәрвакыт гаделлек көтә. Бу очракта үлем җәзасы әнә шул гаделлекнең чагылышына әверелә. Ашка каршы аш, ташка каршы таш. Шул ук вакытта бездәге традицион кыйммәтләр, җәмгыятьтәге заманча кыйммәтләр, гуманизм кыйммәтләрен исәпкә алсак, алар бит үлем җәзасын кире кайтару турындагы фикерләр белән чагышмый. Алай булгач, безнең җәмгыять моңа әзерме? Әле бит дин ягыннан караш та бар. Ә суд хөкем чыгарганда ялгышу ихтималы, тикшерү органнарына ышаныч мәсьәләсен кая куябыз? Кыскасы, бик четерекле сорау. Шуңа күрә бу очракта сәясәтчеләрнең фикере генә җитми. Алар, әлбәттә, «хайп» артыннан бара, җәмгыятьнең күңелен күрергә тели. Әмма шуңа игътибар итик: беренче шок узды, хисләр сүрелә. Хәзер инде бу мәсьәләдә акыл белән эш итүчеләрнең сүзләре ешрак ишетелә башлады.

:: Террорчыларның төп максаты – халыкны куркыту. Үз теләкләренә ирешә алдылармы?

– Әлбәттә, халык курыкты. Әйе, ике елдан артык махсус хәрби операция бара, әмма тыныч шәһәрләрдә шундый куркыныч вакыйгалар булуы күңелгә шом сала. Килешмим, куркыныч хәбәрләргә ияләшеп булмый. Ярамый да. Ияләшәсең икән, дөрес карар кабул итеп тә, саклану чарасы күреп тә булмый.

Мондый зур террактлардан соң без халыкның бер яктан шул ук мигрантлар һәм башка юнәлешләрдә катгый чаралар күрүне таләп иткәнен, икенче яктан берләшүен күрәбез. Бу берләшүне Президент сайлау барышында да күрдек. Илнең иминлеге, киләчәк тормыш кебек төп мәсьәләләрдә фикерләр уртак. Коточкыч фаҗигадә һәлак булганнарны искә алганда, кан тапшырганда, йөзләгән мең кеше ярдәм итәргә әзер булганын, бу хәлләргә битараф түгеллеген күрсәтте. Уртак дошманга каршы тору теләге җәмгыятьне берләштерә.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

КҮҢЕЛ ТЫНЫЧЛЫГЫ КИРӘК

Халык кәефе

Динара ХӘМӘТВӘЛЕЕВА, КФУдагы Психология һәм белем бирү институтының педагогик психология кафедрасы өлкән укытучысы:

– Бүген мәгълүмат ташкыныннан берничек качып булмый. Телисеңме-теләмисеңме, бар нәрсәдән хәбәрдар булып торасың. Бу очракта шунысы мөһим: ишеткән һәр яңалык, хәбәрне күңелеңә якын алырга ярамый. Куркуга бирелеп, киләсе көннән ниндидер куркыныч көтеп утыру да дөрес түгел. Тынычлыкны башка нәрсәдән эзләргә кирәк. Күңел тыныч булсын өчен, күбрәк саф һавада йөрергә тырышыгыз. Спорт белән шөгыльләнегез. Бу бик мөһим. Ник дигәндә, спорт белән шөгыльләнгәндә стресс гормоннары юкка чыга. Үзегездә шундук җиңеллек сизәрсез. Берәр матур әдәби китап уку да артык булмас. Ул уй-фикерләрегезне уңай якка юнәлтәчәк. Начар уйлардан арыну өчен, көндәлек тормышыгызда җаныгызга рәхәт булган шөгыльләргә дә вакыт табыгыз. Иртүк исән-сау уянуыгыз, сау-сәламәт булуыгыз өчен рәхмәт әйтергә дә онытмагыз. Шунысын аңларга кирәк: начар әйберләр без көтү-көтмәүдән генә тормый. Шуңа күрә без үзебезне хәзер, нәкъ менә шушы минутта яхшы хис итәргә тиеш. Моңа уй-хисләребез чиста булганда гына ирешеп була. Үз-үзебезгә, киләсе көнгә ышаныч та шул очракта гына пәйда булачак.

Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ, «Әл-Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы:

– Рамазан аеның соңгы ункөнлеге дә якынлаша. Ураза күңелләребезгә тынычлык кына салып калмый, нәфесебезне дә тәрбияли. Бүгенге тынгысыз көннәрдә бу бигрәк тә мөһим. Шундый чорга дучар булганбыз икән, димәк, тәкъдиребезгә шулай язылган. Аллаһы Тәгалә шушы катлаулы чорда күңелләребезгә тынычлык, иманнарыбызга ныклык насыйп итсен иде. Локман Хәким: «Һәрбер кешенең, ул кем генә булмасын, әгәр аның күңелендә өч әйбер бергә җыелмаса, ул бәхетле булмый. Аның беренчесе – сәламәтлек, икенчесе – ризык булу, өченчесе – җан тынычлыгы», – дигән. Соңгысы аеруча мөһим. Күңел тынычлыгы өчен күп тә кирәкми кебек. Бәлки, Аллаһы Тәгаләбезгә ризалыгыбыз да җитә торгандыр. Кайберәүләр кечкенә генә кыенлыкны да күпертә. Чынлыкта без Аллаһы Тәгаләгә бар нәрсә өчен – сынавына да, шатлыгына да рәхмәтле булырга тиеш. Шул вакытта гына күңелебезгә тынычлык табарбыз. Көннәребезне намаз укып, зекер әйтеп уздырыйк. Пәйгамбәрләребез дә төрле сынау, борчуларга дучар булып торган. Аллаһы Тәгалә, һәрбер авырлыктан соң җиңеллек килер, ди. Шуны онытмасак иде.

Ләйсән ГЫЙМАЕВА, Татарстанның атказанган артисты:

– Бу арада иҗат белән мәш киләбез. Берничә яңа җыр яздырдык. Кызыбыз Таңсылуның да яңа җыры чыкты. Бар нәрсә бар, күңел тынычлыгы гына юк. Башта махсус хәрби операция күңел тынычлыгын алган иде, Мәскәүдәге терракттан соң ул бөтенләй бетте. Мондый чакта якын кешеләрең белән тагын да якынаерга кирәк. Шәхсән үземә Аллаһы Тәгаләдән көн дә сорау, намаз уку күңелгә тынычлык бирә. Аның ризалыгыннан башка бернәрсә дә булмый.

Миләүшә СӘЛАХИЕВА, Яшел Үзән районының Бакырчы авылы клубы мөдире:

– Гаилә елы уңаеннан әби – кыз – оныклардан торган гаиләләр белән «Буыннар чылбыры өзелмәсен» дип исемләнгән бәйрәм чарасы оештырдык. Театр көне уңаеннан балалар белән Фоат Садриевның «Икмәк тәме» әсәрен сәхнәләштердек. Каникул бит, фольклор уеннар уйныйбыз, язгы ташу һәм терроризм турында әңгәмәләр уздырдык. Бу арада бик тынгысыз булды. Күңел әле дә тыныч түгел. Рамазан ае бит, ураза тотабыз, Коръән сүрәләре укып тынычланабыз. Балалар белән эшләү дә тынычлык бирә. Төрле темаларга кереп китеп, рәхәтләнеп аралаша бит алар.

Алинә МӨХӘММӘТДИНОВА, фельдшер (Питрәч районының Тау Иле авылы):

– Яз килгәнгә сөенеп туя алмыйм. Үзем дә шушы ел фасылында туганмын. Тәрәзә төбендәге помидорларым матур гына булып күтәрелеп килә. Көн саен кояш чыгуга, күңел күтәрелә. Шулай да билгесезлек күңелне тырнап тора. Йокыдан торуга, илләр тыныч булсын иде, дип телим. Без дә бит – хәрби бурычлы кешеләр. Әле ялда идем. Эшкә чыкканыма берничә көн генә. Ял дип, фельдшерның ялы да эш белән үтә инде аның. Укол ясатырга да килделәр, яраларны да бәйләдем. Соңгы арада авылда ОРВИ белән авыручылар күбәйде. Монысы сезонлы күренеш инде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ru.freepik

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ТИСӘҢ, ИСЕ ЧЫГА

ТИРЕС ТҮГҮГӘ БӘЙЛЕ ЗАКОННЫҢ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ

Редакциягә Актаныш районында яшәүче Лилия Галиуллина (укучыбыз соравы буенча исеме үзгәртелде. – Авт.) мөрәҗәгать итте. «Безнең утызлап баш терлегебез бар. Шәхси хуҗалык булып исәпләнәбез. Моңа кадәр тиресне билгеле бер урынга түгеп килдек. Тик бер авылдашыбыз моның законсыз гамәл булуын, тиреснең махсус чокырда җыелырга тиешлеген әйтеп, тикшерүчеләр чакырту белән яный. Хәзер ул урынга чыгармый башладык инде, тик бик уңайсыз хәлдә калдык, безнең өчен идеаль вариант юк. Нәрсә эшләргә дә белми аптырыйбыз. Шул закон турында аңлатып язмассызмы икән?»

Соңгы вакытларда тирес түгүгә бәйле сорауларны авылларда еш бирәләр безгә. Аларның күпчелеге «нәрсәгә кирәк» тә, «кемгә кагыла» ише сорауларга кайтып кала. Сүз нинди закон турында бара? Һәм ул нәрсәне аңлата? Без шул турыда белештек.

vk.com

Нидән гыйбарәт?

Билгеле булганча, хайван тиресләрен, чүпләрен, тизәкләрен, мал-туар асларын эшкәртүгә бәйле 248 нче федераль закон узган елның 1 мартыннан гамәлгә керде. Моңа кадәр терлек, кош-корт астыннан алынган калдыклар, тизәкләр ферма янында җыелып, бераздан яки турыдан-туры басуга таратыла иде. Хәзер исә тирес махсус мәйданчыкта җыелырга һәм «өлгергәч» кенә басуга чыгарылырга тиеш.

– 25–30 ел без җирнең уңдырышлылыгын суырабыз. Төрле ашламалар, терлекләрне дәвалаганда төрле препаратлар кулланабыз. Эшкәртелмәгән калдыкларның, юу чараларының барысы да туфракка эләгә. Шуңа күрә законның төп максаты – барлык шартлар үтәлеп ясалган органик ашламаны туфракка кертеп, җирнең уңдырышлылыгын арттыру. Билгеле булганча, туфракка кертелә торган черемә барлык шартлары туры килгән очракта гына файдалы булачак, – дип аңлатты әлеге үзгәрешләрнең максатын Татарстан буенча Россельхознадзор идарәсенең дәүләт ветеринар күзәтчелеге бүлеге башлыгы Идрис Гатин.

Яңа закон буенча, өстәмә продуктлар калдык булып исәпләнми. Терлек тоткан хуҗалыклар (шәхси хуҗалыклардан тыш) калдыкларны җитештерүнең өстәмә продукты буларак куллануны үзләре хәл итәргә һәм бу хакта Россельхознадзорга хәбәр итәргә тиешләр. Ягъни әгәр хуҗалык тиресне өстәмә продукт дип билгели икән, аларны махсус урында кимендә алты ай череткәннән соң, лабораториядә анализлар тапшырып, рөхсәт алгач кына туфракка кертергә тиеш булачак.

– Быелның 31 декабренә кадәр һәр җитәкче безгә үзенең оешмасы турында мәгълүмат җибәрергә тиеш. Әгәр хәбәр итмәгәннәр икән, тирес калдык булып санала, һәм теге яки бу оешманың эшчәнлегенә бәйле шикаять килгән очракта, аның белән Росприроднадзор шөгыльләнәчәк. Ә алар инде зур штрафлар белән эш итә, – ди Идрис Гатин.

Белгеч сүзләренчә, тирес түгелә һәм җыелып килә торган мәйданчык кырыйлары бетоннан яки техник пленка белән эшләнгән булырга тиеш. Табигатькә зыян салынмасын, калдыклар бозылып, сасып, әшәкеләнеп ятмасын өчен, мәйданчык астына кимендә 20 см калынлыкта кызыл балчык түшәлгән булу да шарт. Тирес җыелып тора торган җир дә хуҗалык, фермер исемендә булырга тиеш.

Шунысы да бар: бу закон буенча, юридик оешмаларга шәхси хуҗалыкларга тирес сату тыела. Һәм тиресне һәр фермер үз кырына гына чыгарырга тиеш. Кыры булмаса, башка фермер белән килешү төзеп, шуның басуына чыгара ала.

Чиратта – фермерлар

Әлеге үзгәреш җилләре фермерларга, эре хуҗалыкларга һәм агрохолдингларга кагыла. Тик Идрис Гатинның тел төбеннән аңлашылганча, әлегә республикада базларны эшләп куйган, үрнәк итеп күрсәтерлек фермер хуҗалыклары юк. Әлегә бөтенесе дә кызыксыну, өйрәнү, белешү этабында.

– Былтыр да, быел да бу таләпләрне үтәмәгән хуҗалыкларга штрафлар салмадык, чөнки ул күчеш, күзәтү чоры иде. Теләсә кая тирес түгү очраклары буенча шикаятьләр алынган очракта без әлегә кисәтү генә ясый килдек. Штрафны бары тик прокуратура органнары гына сала ала иде. 2025 елдан бу таләпләрне кискен бозучыларга без дә җитди чаралар күрә башлаячакбыз, – диде Идрис Гатин.

Тирес анализларын алыр өчен пробаларны Татар төбәкара ветеринария лабораториясенә китерәләр. Оешманың директор урынбасары Айдар Садриев та проба китерүчеләрнең күпчелеге эре хуҗалыклар булуын әйтте.

– Фермерлар әлегә моның җитдилеген аңлап бетерми. Ә эре хуҗалыклардан пробаларны көн саен алабыз, – диде ул.

Димәк, бүгенме-иртәгәме, фермерларга да яңа таләпләр буенча эшли башларга туры киләчәк. Күпләрнең быелдан фермер эшчәнлеген ябулары яки шәхси хуҗалыкка күчүләренең дә бер сәбәбе шул булырга мөмкин. Фермерлар эшчәнлегенә карата таләпләр артуны соңгы вакытларда үзләреннән дә аеруча еш ишетергә туры килә. Яңа таләпләр буенча эшләр өчен акча янчыгының да калын булуы кирәк шул.

Бер закон ныклап торып эшли башлаганчы, Дәүләт Думасы депутатлары кагыйдәләрне үтәмәүчеләргә штраф салу турында закон проектын тәкъдим иткән, дип хәбәр итә «Парламентская газета». Әгәр өстәмә продуктлардан файдалану эпидемиягә, яисә экологиягә зыян салуга китерсә, 600 мең сумга кадәр штраф яный. Вазыйфаи затлар өчен минималь штраф күләме 30–40 мең сум булса, эшмәкәрләр өчен бу 250–350 мең сумны тәшкил итәргә мөмкин.

Фикер

**Рәмис МИНГАТИН,
Аксубай районының
Яңа Дума авылы фермеры:**
– Бу закон турында хәбәрдар без, аңлаттылар, тик әлегә мәҗбүриләми торалар. Ләкин мин моның ничек буласын күз алдыма китерә алмыйм. Безгә бетоннан өч баз ясарга, тиресне шунда салып таптарга һәм кемгәдер алып барып күрсәтергә туры киләчәк. Рөхсәт бирсәләр, сибәбез, юк икән, тирес шул килеш торачак. Мин ашлама белән эшләмим, кырларга бары тик тирес кенә чыгарам. Шулай итеп тә бик яхшы уңыш алам. Бу үзгәрешләр миңа мәшәкать кенә тудырачак. Миңа кирәкме ул? Әлбәттә, юк.

**Камил ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,
Балык Бистәсе фермеры:**
– Иртәме-соңмы безгә бу эш тәртибенә күчәргә туры киләчәк. Мин инде бу мәсьәләгә җитди карап, белешеп тә йөри башладым. Тик әлегә җир булмау гына туктатып тора. Чокырын казып, урынын булдырырсың да, законсыз, дип штраф салып китсәләр, нишләрсең? Ныклап өйрәнә башлагач, законның чиле-пешле икәнлеге аңлашыла.

Тирес түгүгә бәйле төп 5 сорауга җавап

НӘРСӘ ӨЧЕН КИРӘК?
Органик ашламаны туфракка кертеп, җирнең уңдырышлылыгын арттыру өчен.

КЕМНӘРГӘ КАГЫЛА?
Терлекчелек, кошчылык, дуңгызчылык, атчылык белән шөгыльләнүче фермер һәм агрохолдинглар, эре хуҗалыклар, кооперативлар, эшмәкәрләр эшчәнлегенә.

ТИРЕС ҖЫЕЛЫП ТОРГАН МӘЙДАНЧЫККА ТАЛӘПЛӘР НИНДИ?
Тирес түгелә һәм җыелып килә торган мәйданчыкның кырыйлары бетоннан яки техник пленка белән эшләнгән булырга тиеш. Табигатькә зыян салынмасын, калдыклар бозылып, сасып, әшәкеләнеп ятмасын өчен, мәйданчык астында кимендә 20 см калынлыкта кызыл балчык түшәлгән булу да шарт.

ОРГАНИК ТИРЕСНЕ ТАРАТУГА НИНДИ ТАЛӘПЛӘР?
Тирес туфракка кимендә алты ай торып өлгергәннән соң гына, торак йортлардан кимендә 300 метр ераклыкта таратыла. Кар катламының биеклеге 20 см һәм аннан да азрак булганда, җир асты һәм җир өстендәге су объектларына туклыклы матдәләр юылып төшүне булдырмау шарты белән туфракка кертү.

ЛАБОРАТОРИЯ АНАЛИЗЛАРЫ НИЧӘ СУМ?
Бер проба алу – 15700 сум.

1 апрель | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.40 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
00.20 «Каравай» 6+
00.45 «Җырлыйк әле!» 12+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12 +
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
9.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТАКСИ ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Владимир Познер. 90 минут» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
09.55 О самом главном 12+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «НЕУКРОТИМАЯ НЕУПОКОЕВА» 16+
23.30 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.05, 13.55, 15.45, 04.00 Новости 0+
07.05, 19.00, 21.25, 23.45 Все на Матч!
10.10 Лица страны 12+
10.30 «Вы это видели» 12+
11.35 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
12.35 Смешанные единоборства. Э. Бланчфилд – М. Фирот. UFC 16+
14.00 «Есть тема!»
15.25 Специальный репортаж 12+
15.50 «Громко»
16.55 Футбол. «Кубань» – «Динамо». МЕЛБЕТ-Первая Лига
19.25 Баскетбол. ЦСКА – «Локомотив-Кубань». Единая лига ВТБ
21.45 Футбол. «Интер» – «Эмполи». Чемпионат Италии
0.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
01.00 География спорта 12+
01.30 Футбол. «Штутгарт» – «Хайденхайм». Чемпионат Германии 6+
03.30 «История Хуана Мануэля Фанхио» 12+
04.05 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. 1/4 финала 6+

НТВ
04.55 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЧЕРНОЕ СОЛНЦЕ» 16+
22.15 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» 16+
01.50 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30, 05.35 По делам несовершеннолетних 16+
07.25, 04.20 Давай разведёмся! 16+
08.25, 02.40 Тест на отцовство 16+
10.40, 23.05 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.15 «Порча» 16+
12.55, 01.15 «Знахарка» 16+
13.30, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.15 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СЕМЕЙНЫЕ ПРИЗРАКИ» 16+
05.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
05.45 «Герой 115» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 20.10 «По горячим следам» 16+
11.20, 01.00 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ» 12+
13.40, 04.00 «РАЗВЕДЧИКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Ленинград. Снять блокаду» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.25 Сыновья уходят в бой 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «КАДКИНА ВСЯКИЙ ЗНАЕТ» 12+
02.10 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
03.40 «Москва – фронту» 16+

2 апрель | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
10.40, 17.10 «ХЫЯЛ = МАКСАТ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Әдәби хәзинә» 6+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Национальный калейдоскоп» 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Ватандашлар» 16+
23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ
05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
9.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТАКСИ ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
09.55 О самом главном 12+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «НЕУКРОТИМАЯ НЕУПОКОЕВА» 16+
23.30 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.05, 15.45, 04.00 Новости 0+
07.05, 15.00, 16.50, 19.30, 22.00, 00.30 Все на Матч!
10.10, 15.25 Специальный репортаж 12+
10.30 Лыжные гонки. ФосАгро Кубок России
15.50 Футбол. МИР РПЛ. Обзор тура 6+
17.15 Футбол. «СКА-Хабаровск» – «Динамо». FONBET Кубок России. 1/4 финала
19.45 Футбол. «Химки» – «Ростов». FONBET Кубок России. 1/4 финала
23.00 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 3
01.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
01.30 Баскетбол. ЦСКА – «Локомотив-Кубань». Единая лига ВТБ 6+
03.30 «История Хуана Мануэля Фанхио» 12+
04.05 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. 1/4 финала 6+

НТВ
04.50 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЧЕРНОЕ СОЛНЦЕ» 16+
22.15 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» 16+
02.45 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.25, 04.30 Давай разведёмся! 16+
08.25, 02.50 Тест на отцовство 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.50, 01.30 «Знахарка» 16+
13.25, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СЕМЕЙНЫЕ ПРИЗРАКИ» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.25 По делам несовершеннолетних 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 19.55 «По горячим следам» 16+
11.20, 01.00 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ» 12+
13.40, 04.00 «РАЗВЕДЧИКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Ленинград. Снять блокаду» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «КАЗАЧЬЯ ЗАСТАВА» 12+
02.05 «КАДКИНА ВСЯКИЙ ЗНАЕТ» 12+
03.20 «Отечественное стрелковое оружие» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 1 апрель
06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуаль әңгәмә»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10 «Елмаеп яшик!»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Аманулла. «Мактанчык әтәч». Әлмәт ТДДТ спектакле
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 2 апрель
06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Мөнир Мазунов шигырьләренә җырлар

Чәршәмбе, 3 апрель
06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Юлләр чатында»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.20 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Олег Лундстрем җитәкчелегендәге Татар эстрада оркестры язмалары

Пәнҗешәмбе, 4 апрель
06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Перекресток»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар»

Җомга, 5 апрель
06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00, 20.40 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Популяр музыка концерты

Шимбә, 6 апрель
8.10 Дилә Булгакова әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Ләбиб Айтуганов. «Әгәр сөйсәң». Радиокомпозиция

Якшәмбе, 7 апрель
08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЛАЗЕРЛЫ ДӘВА

Соңгы арада күзләргә лазер ярдәмендә операция ясату популярлашып китте. Модага иярү галәмәтеме бу? Лазер ярдәмендә күзләргә операция ясауның нинди уңай һәм тискәре яклары бар?

Казан дәүләт медицина академиясенең офтальмология кафедрасы ассистенты Элина МИНХУҖИНА белән шул хакта сөйләштек.

:: Ни өчен күзләргә лазер ярдәмендә коррекция ясау соңгы арада шулкадәр популярлашты?

– Лазер ярдәмендә күзгә операция – күз күрүен яхшыртырга мөмкинлек бирүче югары технологияле, нәтиҗәле ысул. Бу ысул бүген, чынлап та, бик популяр. Безнең республика офтальмология хастаханәсендә дә көненә шундый 25–30 операция ясала. Бу ысул белән, нигездә, 40 яшькә кадәрге кешеләрне дәвалыйбыз. Әлеге ысул ярдәмендә кыска гына вакыт аралыгында ерактан күрмәү яки астигматизм (фокус югалу) кебек күз авыруларыннан котылырга була. Лазер ярдәмендә ясала торган операция, күп дигәндә, 5–10 минут дәвам итә. Бу ысул, иң беренче чиратта, әнә шул ягы белән алдыра.

:: Лазер ярдәмендә күзгә коррекция ясауның файдасы нидә?

– Әлеге төр операция ярдәмендә кыска вакыт эчендә иң зур хәрефләрне генә һәм ерактан нибары ун процент чамасы гына күргән кеше дә операциядән соң 100, хәтта 120 процентка кадәр күрә башлый. Шул рәвешле кеше өчен бик зур мөмкинлекләр ачыла. Кеше кабаттан дөньяның ямен тоеп, күреп яши башлый. Шулай ук операция ясар алдыннан күзгә авыртуны баса торган тамчылар салалар. Шуңа күрә аны ясаганда авырту сизеләчәк дип тә куркасы юк. Аннары лазер ярдәмендә күзгә операция ясау кайчак матди яктан да отышлырак чыга. Мисал өчен, астигматизм диагнозы куелган кешеләр өчен чыгарылган линза һәм күзлекләр бик кыйммәт. Өстәвенә кеше аларга бик озак һәм авырдан ияләшә. Шуңа күрә бу очракта лазер ярдәмендә күзгә операция ясату күпкә отышлырак.

:: Шулай да, ничек кенә булмасын, теләсә кайсы операция организм өчен зур сынау инде...

– Килешәм. Лазер ярдәмендә операция ясаганнан соң да, гадәттә, күзгә ком салган шикелле, анда нәрсәдер бар кебек тоела. Әмма бу уңайсызлыклар икенче көнгә кими. Бер ай дәвамында ул тулысынча юкка чыга.

:: Ишеткәнегез бардыр: күпләр лазер ярдәмендә операция ясаган табибларның барысы да күзлек кия, димәк, бу алым зыянлыдыр, дип шикләнә. Лазер ярдәмендә операция ясау күзләргә зыян да салырга мөмкинме?

– Әйе, кайбер күз табиблары үзләре дә күзлек кия. Әмма шәхсән мин белгән барлык яшь табиблар күзенә лазер ярдәмендә операция ясатты. Ә менә яше 40тан узган табибларның күбесе күзлектән йөрүне кулайрак күрә. Ник дигәндә, бу чорда инде күздә табигый үзгәрешләр башлана. Шуңа күрә әлеге очракта операциянең бу төре бик килешеп бетми. Чынлыкта яшәү рәвешең күзлек, линзага бәйле булу бик кыен. Алар бик нык чисталык сорый. Ник дигәндә, күзлекне гел чистартып тормасаң, линзаны чиста кул белән кимәсәң, күзне ялкынсындырып, тагын да җитдирәк авырулар китереп чыгара ала. Әйткәнемчә, алар кесәгә дә суга.

:: Нинди очракларда күзләргә лазер ярдәмендә коррекция ясау, гомумән, киңәш ителми?

– Операция ясатыр алдыннан кеше иң элек диагностика узарга тиеш. Бу бик мөһим. Ник дигәндә, күзнең мөгез катлавы юка булганда барлык дәвалау ысуллары да килешеп бетми. Шуңа күрә җитди күз авырулары, яман шеш, шикәр чире, ревматоидлы артрит кебек чирләр вакытында күзгә лазер ярдәмендә операция ясарга ярамый.

Бу ысул йөкле һәм бала имезүче хатын-кызларга да киңәш ителми. 18 яше тулмаган балаларга да лазер ярдәмендә операция ясарга ярамый. Ник дигәндә, бу чорда күз алмасы үсә, формалаша. Яше 45тән узган кешеләргә дә лазер ярдәмендә күз күрүен яхшыртырга киңәш ителми.

:: Хатын-кызга күзләренә лазер ярдәмендә операция ясаткач, бала тапса, күз күрүе начарланачак, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Йөклелек чорында, бала тапкач, хатын-кыз организмында бик зур гормональ үзгәрешләр була. Шуның йогынтысында хатын-кызның лазер белән операция ясалган күзе дә начаррак күрә башларга мөмкин. Әмма ул коточкыч дәрәҗәдә начарланмый. Шуңа күрә бу очракта куркырга сәбәп юк.

:: Ни өчен лазер операциясе ясарга ике атна кала линзасыз йөрергә кушалар?

– Операция алдыннан күзләрне, бигрәк тә аның мөгез катлавын яхшылап тикшерәләр. Линза исә менә шул тикшерү нәтиҗәләренә тискәре йогынты ясарга мөмкин. Ә күзләрне тикшергәндә хата китсә, операция дә уңышсыз чыгарга мөмкин.

Күзләр яхшы күрсен өчен киңәшләр

Күзләргә дә витамин кирәк! Иң элек әнә шул хакта онытмагыз. A, E, C һәм B витаминнары күзләргә аеруча файдалы. Алар кишер, петрушка, диңгез ризыклары, кара җиләктә, чикләвек, йомырка, ярмаларда бар. Күзләр яхшы күрсен өчен көненә 1 стакан кишер суы эчү дә җитә.

Көндәлек тормышта кеше барлык мәгълүматның 75 процентын күз аша ала. Дөрес тукланмау, пычрак тирәюнь, озак итеп телевизор, гаджетка карау күзгә бик начар тәэсир итә. Компьютерда эшләгәндә монитордан 50–70 сантиметр ераклыкта утырырга һәм һәр сәгать саен күзне 5–10 минут ял иттереп алырга кирәк. Күзләрне ял иттерү өчен вакыт-вакыт күзләрне еш-еш ачып йомарга яисә берничә секунд йомып торырга кирәк.

Тәмәке тарту да күзгә зур зыян сала. Никотин күзнең яктылык нурларын кабул итүче әчке сүрүенең (сетчатканың) кан йөрешен боза.

Күзләр өчен файдалы салат та ясап ашый аласыз. Моның өчен 1әр өлеш угычтан уылган кишер, вакланган күрәгә, эфлисунга 1 аш кашыгы бал кушып болгатырга, шуны 10 минуттан ашарга кирәк. Салатны бер ай дәвамында көн дә ашасагыз, файдасы озак көттермәс.

Киңәш-табыш

МАЙЛЫ ТОЗ АЯКЛАРГА ХӘЛ КЕРТӘ

Арыган аякларга хәл кертү өчен киң таралган чара бар. 1 стакан чистартылмаган көнбагыш маенда 1 чәй кашыгы аш тозын эретегез. Аны бик озак болгатырга кирәк. Кич белән шуны аяк табаннарына һәм балтырларга яхшылап ышкыгыз, массажлагыз. Аннары аякка полиэтилен пакет өстеннән җылы оекбаш киеп, 30–40 минут тотыгыз һәм кайнар су белән юып йокларга ятыгыз. 2–3 көн рәттән шулай эшләргә кирәк.

Белеп тор!

Һәрберсендә шифа бар

Чикләвек – көндәлек рационда булырга тиешле иң файдалы ризыкларның берсе. Аның һәр төре организм өчен үзенчә шифалы.

☑ **Миндаль.** Табиблар йөрәк авыруларыннан интегүчеләргә атнасына кимендә 60 грамм миндаль ашарга киңәш итә. Миндаль фосфор, калий һәм тимергә бай.

☑ Көнгә 20 **кешью** ашасагыз, организмга бер тәүлеккә җитәрлек тимер керәчәк. Бу чикләвек кеше иммунитетын ныгыта, йөрәк эшчәнлеген яхшырта һәм хәтта теш авыртуын баса.

☑ **Фисташка** – түбән калорияле, минераллар, витаминнарга бай чикләвек. Әмма аның белән артык мавыгырга кирәкми. Өлкән кеше көнгә күп дигәндә 15 фисташка чикләвеге ашарга тиеш. Бу чикләвек ашкайнату системасы, сулыш юллары, азканлылык авыруларын дәвалаганда ярдәм итә. Токсикоз вакытында да булыша ул. Моннан тыш фисташка ир-атларның репродуктив сәләтен арттыра.

☑ **Фундук** A һәм E витаминнарына бай. Ул баш мие эшчәнлеген яхшырта.

☑ **Әстерхан чикләвеге** азканлылыктан, нерв системасы авырулары, йөрәк һәм ашказаны авыруларыннан ярдәм итә.

☑ **Кедр чикләвеге** витаминнар, макро- һәм микроэлементларга бай булуы белән аерылып тора. Бигрәк тә балаларга һәм өлкәннәргә файдалы ул.

☑ **Арахис** – антиоксидант. Ул күрүне, ишетүне һәм хәтерне яхшырта.

Валентина СЕМЕНОВА

ЯРТЫ СҮЗЕ ДӘ ҖИТӘ

Мошенниклар акча урлауның яңа ысулларын табып кына тора. Гадәттә алар, шалтыратып, үзләрен полиция, Пенсия фонды, банк хезмәткәре, дип атый, ничек тә алдарга тырыша. Кайберләребез шуларга ышанып та куя. Ә бит кемнең кем икәнен беренче җөмләсеннән үк чамаларга була. Түбәндәге сүзләрне ишетүгә, сөйләшүне шундук туктатыгыз, дип кисәтә белгечләр.



vk.com

1 «Мин – Үзәк банк хезмәткәре».
Үзәк банк хезмәткәрләре беркайчан да кемгә дә булса шалтыратмый. Бары тик банк бүлегенә мөрәҗәгать итсәң генә алар теге яки бу мәсьәләгә ачыклык кертә.

2 «Сезнең исемгә кредит алу өчен гариза тапшырылган».
Шул рәвешле мошенниклар, янәсе, кредитның инде рәсмиләштереп куелганлыгын хәбәр итә. Әмма сез гариза тапшырмаган икән, кредит турында нинди сүз булырга мөмкин?! Дөреслекне табарга тырышмагыз: телефонны өзегез дә – шуның белән шул.

3 «Махсус» яки «имин счет».
Һавадан алынган төшенчәләр бу. Мошенниклар, янәсе, акчагызны урларга маташалар, шуңа күрә аны менә шушы «имин» счетка күчерегез, ди. Тик дөньяның бер генә банкында да мондый счет юк!

4 «Тикшерү бара/ Беркемгә дә әйтмәгез/Мошенникларны табарга ярдәм итегез».
Хокук саклау органнары хезмәткәрләре телефон аша тикшерү үткәрергә маташмый, җинаятьчеләрне тотуда ярдәм сорамый. Кирәк булса, полиция бүлеге сезгә повестка җибәрәчәк.

5 «Шикле гамәл күрдек, акчагызны урларга маташалар».
Мондый очракларда банк хезмәткәрләре шикле гамәлләрне үзләре үк туктата, бу хакта онлайн кушымтада хәбәр итә яки банкның рәсми номерыннан шалтырата. Кешедән алар картасы яки счеты буенча нәрсәдер эшләүне беркайчан да сорамый.

6 «Мин – иминлек хезмәте хезмәткәре, финанс иминлеге белгече».
Аферист шул рәвешле карта мәгълүматларын, яшерен кодын, смс-хәбәр белән килгән кодны белергә маташачак. Әле тагын картада калган акча күләмен, тагын нинди банк счетлары на ия булуыгызны сорарга мөмкин. Шуны онытмагыз: чын банк хезмәткәре счетыгызда акчаны болай да күреп-белеп тора. Шуңа күрә аңа бер нәрсәне дә ачыкларга кирәкми.

7 «Смс-хәбәр белән җибәрелгән кодны әйтегез».
Бу очракта сөйләшүне, тасма теллеләнеп, төрлечә башларга мөмкиннәр. Әйтик, бүген юбилей, шуңа күрә банк сезгә акча бүләк итә, моның өчен смс-хәбәр белән юлланган кодны әйтегез, дип. Әйтә күрмәгез! Мондый код акча алу өчен кул куюга тиң!

8 «Сим-картагызның гамәлдә булу вакыты чыга».
Белеп торыгыз: бер генә сим-картаның да гамәлдә булу вакыты чикләнмәгән.

Телефоннан шушы сүзләрне ишетүгә, сөйләшүне туктатыгыз. Теләгегез һәм вакытыгыз булса, банкның иминлек хезмәтенә шалтыратып, кырыгалдарларның телефон номерын хәбәр итәргә мөмкин.
Мошенниклар телефон аша гына түгел, мессенджерлар аша да шалтырата: аккаунтлар булдырып, «аватарка»га банк яки хокук саклау органы эмблемасын куя. Мондый шалтыратулар яки хәбәрләргә беркайчан да җавап бирмәгез, тәкъдимнәре белән килешмәгез! Хәтта алар бик отышлы тоелса да! Кирәк икән, үзегез үк банкның рәсми номерына шалтыратыгыз. Банк хезмәткәре үзегездә кызыксыну тудырган барлык акцияләр һәм тәкъдимнәр турында энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирәчәк.

Кирәге чыгар

Сары томшык

Озакламый авылларга инкубатор чебиләре кайта башлаячак. Ә аларны, бигрәк тә йомыркадан гына чыкканнарын үстерү җиңел түгел. Бер тәүлеклек чебиләр үстерү буенча зур тәҗрибәгә ия булган Елена АЛЕКСЕЕВА киңәшләрен бирeп үтәбез.

Иң мөһиме – беренче көннәрдә аларны бик җылыда тотарга кирәк. Тартма төбенә чүпрәк җәеп, почмакларына кайнар су тутырылган ике өч литрлы банка куярга мөмкин. Банкаларны, сары томшыклар пешмәсен өчен, чүпрәккә төрергә. Суынгач, суын алыштырырга.

Чебиләргә 3 тәүлек дәвамында йомырка ашатам. Аны каты итеп пешерәм, ваклап турыйм. Шуннан соң уылган кишер, балык шулпасында ботка (изелеп пешмәскә тиеш, юкса томшыкларына ябышачак) пешереп ашатам. Бик нык вакланган кукуруз, бодай, тары ярмасы белән сыйлыйм. Тарыны әйбәтләп юганнан соң кайнар суга салырга һәм кайнатып чыгарырга кирәк. Шуннан, сөзеп, суынгач һәм кипкәч кенә чебиләр алдына куярга.

3–5 көнлек булгач, пипеткадан томшыкларына берәр тамчы тривитамин (атнага 1 тапкыр) тамызам. Чебиләрне терелтә, ныгыта ул.

Беренче көннәрдә левомицитинлы кайнаган су (1 литрга 1 сәдәф) гына эчертәм. Шулай ук гөлҗимеш тонәтмәсе яки алсу төстәге марганцовка эремәсе бирергә мөмкин.

15–20 көнлек булгач, урамга кояшлы урынга чыгарам. Яшь клевер, тузганакны ваклап турап бирәм.
Бу киңәшләрне тотканда, чебиләр, авырмыйча, матур булып үсәчәк.

Кайвакыт тупас ашлыктан, пычкы чүбе, салкын судан чебиләрнең бүксәсе тыгыла. Бу очракта алар сулпәнәя, азык чүпләми башлый. Нишләргә? Шприцның энәсен алып, җылы су тутырырга (марганцовкалы булса да ярый) да, томшыгын ачып, суны әкрен генә кертергә. Чебинең бүксәсе бушанып, чистарып калачак. Шулай ук берничә тамчы үсемлек мае да кертергә мөмкин.

Мең дә бер киңәш

Термос чистарту

Вакытлар узу белән термос төбе һәм кырыйлары карала. Бигрәк тә – еш кына үләннәр төнәтмәсе ясаганда. Чистартуның сере болайрак. Термоска кайнар су агызып, бераз гына чәй содасы өстибез дә 2 сәгать тотабыз. Шуннан соң берәр уч дөге салып, җинелчә генә селкибез. Барысын да түгеп, чиста су белән чайкап алабыз. Термос эче көзге кебек ялтырап калачак!

Тәмле булсын!

ЭРЕТЕЛГӘН СЫР БЕЛӘН ВИТАМИНЛЫ САЛАТ

Гүзәл ШӘРӘФИЕВА рецепты
Кирәк: *3 эре йомырка, 2 данә эретелгән сыр, 1 баш эре сарымсак, 1 кыяр, бераз суган кыягы, 2 аш кашыгы майонез, тәменчә тоз, борыч, горчица (пастасы), петрушка.*
Йомырканы каты итеп пешереп, сыр белән эре тишекле угыч аша чыгарабыз. Сарымсакны чистартып изәбез. Кыярны шакмаклап, суган кыягын ваклап турыйбыз. Барысын да бер савытка салып, тоз, борыч, горчица, майонез өстибез һәм болгатабыз.

Укучы хаты

КАПЧЫК КИДЕРӘМ

Помидор, кыяр, ташкабак, кайбер чәчәк кәлшәләрен торфтан ясалган савытларга утыртам. Бик уңайлы: савыты-ние белән күчереп утырту нәтиҗәсендә тамырларына зыян килмичә кала. Ләкин бер тискәре ягы бар: мондый савыттагы туфрак тиз кибә. Шуңа күрә, үсенте сулмасын өчен, көн саен су сибеп торырга кирәк.
Туфракта дымны озаграк саклау өчен, савытларны полиэтилен капчыкларга урнаштырам мин. Болай эшләгәндә, туфрактагы дым берничә көн югалмый.

Зөлфия ӘХМӘТОВА. Аксубай районы

БӘРГӘЛӘНМӘСЕН КҮҢЕЛ!

Барысы да бар, тик юк тынычлык. Хәзерге заманда бу сүзләрне бик күпләрдән ишетәсең. Юкка гына күңел тынычлыгын олы бәхеткә тиңләмиләр, тормышта иң мөһиме дә шул, димиләр инде. Күңел тынычлыгына ничек ирешергә?

Бу һәм башка сорауларга җавап эзләп, мөхәррир, дини тапшырулар алып баручы Ленар ХАМАТОВка мөрәҗәгать иттек.

ru.freepik.com

:: Кеше курыкса, башына кайгы төшсә, күңел тынычлыгын югалта. Гомумән, күпләр хәзер тынычлык юклыктан зарлана. Ни өчен шулай икән?

– Күңел тынычлыгы югалуда төп сәбәп – гөнаһлар һәм тәүбә кылмау. Ничек кенә гади яңгырамасын, бу шулай. Монда зур гөнаһлардан битәр кечкенәләре турында сүз. Бер гөнаһ кылып, күңелдә кара тап барлыкка килергә мөмкин. Күңел пычранган саен, тынычлык та югала. Пәйгамбәребездән (с.г.в.) «Гөнаһ нәрсә ул?» – дип сорагач, ул: «Гөнаһ ул – шундый нәрсә: аннан синең вөҗданың газаплана». Кеше, гөнаһ кылып йөреп, тәүбәгә килми, әмма аның табигате, вөҗданы моңа каршы килергә мөмкин. Күңел шуннан бәргәләнә. Тәүбә кылсак, күңел тынычлыгын да кайтара алырбыз.

Икенче сәбәп – безнең тәвәккәллек югалды.

«Мөселман кешесенең хәле гаҗәптер. Аңа яхшылык килсә, ул: «Аллаһка шөкер», – ди. Ул аны Аллаһтан дип кабул итә. Шул рәвешле ул тәкәбберләнми. һәм Аллаһка шөкер итүе белән ул үзенә савап та ала. Әгәр кайгы килсә дә, кеше: «Аллаһка шөкер», – дисә, ул тагын савап алыр», – ди пәйгамбәребез (с.г.в.). Ягъни яхшысы да, яманы да – Аллаһтан. Игелек килсә дә, начарлык килсә дә – Аллаһтан. Мөселман кеше моны аңлый, сынау яисә кәффарәт буларак кабул итә һәм моңа шөкер кыла. Шул рәвешле аның күңеле тыныч кала.

Тагын бер сәбәп итеп гыйбадәтебезнең сыйфатын атарга була. Әйтик, намаз укыйбыз да рамазан аенда ураза тотабыз. Әмма бит без, күңел тынычлыгына ирешик дисәк, шушы гыйбадәтләрдән тыш нәфел гыйбадәтләрен дә кылырга тиешбез. Әйтик, уразаны ел дәвамында да тотарга була. Рамазан аенда кешеләр дә үзгәрә, моны барыбыз да сизәдер. Ураза – рухны, нәфесне чистарта торган гамәл. Нәфес басылып, рухи дөньябыз өстенрәк чыкса, күңелебез янә чистара. Нәфел гыйбадәтләре кешегә тынычлыкны сакларга, бәрәкәтне арттырырга бик булыша.

:: Күңел тынычлыгына ничек ирешергә?

– Үзебезнең тормышка зекерне кертергә кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: «Әллә Аллаһны зекер итү белән күңелләр тынычланмыймы?» – ди. Аллаһны искә алырга кирәк. «Сөбханаллаһ», «Аллаһу әкбәр», «Әлхәмдүлилләһ», «Ләә иләәһә илләллааһ» дигән тәһлилне кабатлау һәм башкасын әйтеп искә алырга мөмкин. Яисә Аллаһ үзе барлыкка китергән нәрсәләргә күз салу (табигать, кояш, ай, агачлар, һавага), аларга карап, Аллаһ турында уйлану, «Кара әле, боларны барысын да Аллаһы Тәгалә барлыкка китергән бит!» – дию дә Аллаһны зекер итү булыр. Боларны эшләү өчен ниндидер аерым вакыт кирәк тә түгел бит. Иртән тордың – әйтәсең, машинада барасың – әйтәсең. Шул рәвешле күңел тынычлыгын кайтарасың.

Күңел тынычлыгына ирешер өчен, Коръән укырга өйрәнергә кирәк. Гарәпчә укырга тырышу хәерле. Коръән укыганда кеше, бирелеп, мәгънәләренә төшенеп укырга тырыша икән, аның күңеле чистара.

Бу җәһәттән бер кыйсса бар. Бабай белән онык Коръән укыйлар икән. Малай: «Бабай, гел Коръән укыйбыз, әмма гарәпчә белмибез. Аңламагач, аннан файда, мәгънә бармы соң?» – дип сорый икән. Бабасы: «Мин бу сорауга җавап бирермен, бар, ташкүмер ташый торган чиләк белән су алып мен әле», – дип, баланы су алырга җибәрә. Чиләк астында тузан коелып барсын өчен махсус челтәре була. Малай: «Моңа бит су салып булмый», – дип тә карый, әмма бабасы сүзенә каршы килми. Суны ала, бабасы янына менгәнче, суы агып та бетә. Күп тапкыр шулай эшләгәннән соң, онык, арып: «Моның мәгънәсе ни инде?» – дип сорый. Бабасы: «Чиләгеңә кара әле», – ди икән. Баксаң, кап-кара чиләк чип-чиста булган. «Күрәсеңме, безнең күңелебез дә шушы чиләктәй кап-кара булырга мөмкин, ә менә Коръән уку әкрен-әкрен генә безнең йөрәкләрне чистартачак», – дип аңлаткан.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Апрель аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Дүш	02:58	05:13	16:12	18:22	20:11
2	Сиш	02:55	05:10	16:14	18:24	20:13
3	Чәрш	02:51	05:08	16:15	18:26	20:16
4	Пәнҗ	02:48	05:05	16:17	18:28	20:19
5	Җом	02:44	05:03	16:18	18:30	20:21
6	Шим	02:41	05:00	16:19	18:32	20:24
7	Якш	02:37	04:57	16:21	18:34	20:27
8	Дүш	02:33	04:55	16:22	18:36	20:30
9	Сиш	02:29	04:52	16:24	18:38	20:33
10	Чәрш	02:26	04:50	16:25	18:40	20:36
11	Пәнҗ	02:22	04:47	16:27	18:42	20:38
12	Җом	02:18	04:45	16:28	18:44	20:41
13	Шим	02:14	04:42	16:29	18:46	20:44
14	Якш	02:10	04:40	16:31	18:48	20:47
15	Дүш	02:05	04:37	16:32	18:50	20:50
16	Сиш	02:01	04:35	16:33	18:52	20:54
17	Чәрш	01:57	04:32	16:35	18:54	20:57
18	Пәнҗ	01:53	04:30	16:36	18:56	21:00
19	Җом	01:48	04:27	16:37	18:58	21:03
20	Шим	01:43	04:25	16:39	19:00	21:07
21	Якш	01:39	04:22	16:40	19:02	21:10
22	Дүш	01:34	04:20	16:41	19:04	21:13
23	Сиш	01:29	04:18	16:43	19:06	21:17
24	Чәрш	01:24	04:15	16:44	19:08	21:20
25	Пәнҗ	01:18	04:13	16:45	19:10	21:24
26	Җом	01:13	04:11	16:46	19:12	21:28
27	Шим	01:07	04:08	16:48	19:14	21:32
28	Якш	01:01	04:06	16:49	19:16	21:35
29	Дүш	00:54	04:04	16:50	19:18	21:39
30	Сиш	00:47	04:01	16:51	19:20	21:43

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Сорау – җавап

Хәзрәт җавап бирә

Көндәлек тормышыбызда күңелне борчыган сораулар туып кына тора. Араларында дингә кагылышлылары да байтак. Шуны истә тотып, сәхифәбездә махсус рубрика башлап җибәрдек. Дингә кагылышлы соравыгыз булса, аны 89534975861 («Ватсап») аша безгә юллый аласыз.

Укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИНОВ җавап бирә.

? Фидия сәдакасын һәркем түләргә тиешме? Мәсәлән, мин пенсиядә ди, авыру сәбәпле, ураза тота алмыйм, өстәмә керемем юк. Мин аны түләргә тиешме? Нисаб, диләр, нәрсә соң ул? Аңлатсагыз иде.

Исемемне күрсәтмәгез

– Шәригать күзлегеннән карап әйтсәк, беркайчан да терелә алмыйча авыруган кешеләргә һәм олыгаюның соңгы дәрәҗәсенә җитеп, ураза тота алмаганнарга фидия сәдакасын бирү вәҗиб (үтәргә тиешле) санала. Әгәр дә бу кешеләр фидия бирә алмаса, күпме булдыра ала, үзләренә зыян салмаслык дәрәҗәдә сәдака бирергә тиеш. Әгәр алай да булдыра алмасалар, бу очракта бернәрсә бирмәскә дә була. «Нисаб» дигән сүз билгеле бер дәрәҗәгә ирешкән мал, билгеле бер күләмдә байлык дип тәрҗемә ителә. Ул байлык алтын һәм көмештә исәпләнә. Мәсәлән, быелгы зәкят чыгарылырга тиешле нисаб күләме – 495 мең сум. Ягъни берәр кешедә шушы күләмдә мал булса һәм ул кимемәсә, бу кешегә шушы малдан 2,5 процентны фәкыйрьләргә, ятимнәргә, мохтаҗларга бирү вәҗиб санала.

? Намазда яулыкны җәеп ябу мәҗбүриме, өчпочмаклы булса да ярыймы? Ишеткәнем бар иде: әгәр дә яулыкны җәеп япмасаң, фәрештәләр кая кунарга белмәс, диләр.

Мөршидә ИХСАНОВА

– Мөселман хатын-кызның башындагы яулыгы шәригать кануннарына туры килсен өчен, ике шарт үтәлергә тиеш. Беренче шарт: яулык яисә баш киеме биттән тыш барлык чәчне-башны, муеннарны капларга тиеш. Икенче шарт: башка дин тарафдарларының баш киемнәренә яисә яулыкларына охшарга тиеш түгел. Әгәр дә шушы ике шарт үтәлә икән, шушындый яулык яисә баш киеме белән йөрергә рөхсәт ителә. Фәрештәләрнең хатын-кызның башына бәйләгән яулыгына куну-кунмаулары турында хәдисләрдә, аятьләрдә бернинди мәгълүмат юк.

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

И туган тел, и матур тел...

Асылташ



Хатын-кызның язмышы ил, милләт язмышыннан аерылгысыз. Ул – күп рольләрне үзендә берләштерә алган шәхес. Юкка гына туган тел турында сөйләшкәндә дә «ана теле» дип әйтмибез бит, телне балага бирүче кеше дә – хатын-кыз. Милләтебезнең хәзерге асыл затлары – кемнәр, бүгенге заман туташ-ханымнары нинди? Яңа сәхифәбездә әнә шул сорауга җавап табарга тырышачакбыз.

Гүзәлем

жырчы, эшмәкәр, әни

ӘҢГӘМӘНЕҢ ВИДЕО ВАРИАНТЫ

Бизнесвумен, җырчы, ир хатыны, әни... Шушы рольләр арасыннан миңа иң якыны – әни роледер. Балабыз тугач, без гастрольләрне туктаттык, күптән чыккан юк. Бар вакытымны балага багышладым. **БУ МИНЕМ ӨЧЕН БИК МӨҺИМ.** Әнием дә мине сеңлем белән шулай үстерде, буш вакытын безгә багышлады, эш дип чапмады, балаларның киләчәге матур булсын дип тырышты. Бала үскән чакта әти-әнисенә карап үсә инде ул. Үзе гаилә коргач та, шуны кабатлый. **ХАТЫН-КЫЗНЫҢ ТӨП ЭШЕ ДӘ – ӘНИ БУЛУ, ГАИЛӘСЕН КАЙГЫРТУ.**

Безнең гаиләдәге хатын-кызлар – укытучы кешеләр. Ә укытучы ул – үрнәк. Аңа карыйлар, аны бәялиләр. Бала-чага бигрәк тә. Әнием балалар янына гел матур киенеп килергә, сыйфатлы бизәнгечләр, кыйммәтле хушбуйлар кулланырга тырыша иде. Акчалары әллә ни булмаса да, **МАТУР БУЛЫРГА ТЫРЫШТЫЛАР!** Буыннан-буынга күчә бу, без дә бу гадәтне сеңдердек.

Дингә килгәч, эстрададагы образым да үзгәрде, билгеле. **БУ – ХӘЗЕРГЕ ТОРМЫШ РӘВЕШЕМНЕҢ БАШЛАНГЫЧ СУКМАГЫ ИДЕ.** Шул вакытта ук халыктан, аудиториямнән хуплау сүзләре күп ишеттем. Шул көннәрдән башлап көн саен диярлек гүзәл затлардан дингә кагылышлы, киемгә, хәтта тәһарәт алуга бәйле бихисап сораулар алам.

ШУНДЫЙ ЗАМАНДА ЯШИБЕЗ: ХӘЗЕР ХАТЫН-КЫЗ БЕЛӘН ИР-АТ БЕР-БЕРСЕ БЕЛӘН УЗЫША-УЗЫША ЭШЛИ. Бу аңлашыла да. Кешенең яхшы яшисе, сыйфатлы ризык ашыйсы, киенәсе килә.

Бер хәзрәтнең: «Син беләсеңме, бу бит Аллаһның рәхмәте! Синең аша күпме кеше дингә килергә мөмкин!» – дип әйткәне бар. **БУ СҮЗЛӘРНЕ ТӘКӘББЕРЛӘНЕП ӘЙТМИМ, ЮК!** Киресенчә, мин моңа шатланам, моның зур җаваплылык икәнен аңлыйм, моңа рәхмәт әйтәм! Шулай язгандыр: миңа башта эстрадада танылырга кирәк булгандыр, аннан исә кешеләрне дә үз артымнан ияртергә. Безнең иҗатыбыз да хәзер башка юнәлешне алды. Аллаһы Тәгалә безгә күркәм юлларны үзе күрсәтә.

ТЕЛ МӘСЬӘЛӘСЕ, ӘЛБӘТТӘ, МИНЕ БОРЧЫЙ. БАЛАЛАР КҮБЕСЕНЧӘ РУСЧА СӨЙЛӘШӘ. БАЛАБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ СҮЗЕ «ӘНИ», АННАН «ӘТИ» БУЛДЫ. Барыбыз да гаиләдә татарча сөйләшәбез югыйсә! Инде балалар бакчасына йөри башладык... Татар тәркемәнә! Әмма... Монда төп сәбәпнең берсе – контент. Балалар хәзер – интернетта. Ә анда татар телле, сыйфатлы контент аз. **БУ – БАЛАЛАР ГАЕБЕ ТҮГЕЛ.** Зурлар, ягъни без эшләп бетермибез...

ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫ, ДИЮГӘ, ИҢ ЭЛЕК САБЫРЛЫК СЫЙФАТЫН ТЕЛГӘ АЛАСЫ КИЛӘ. НИ ӨЧЕН ШУЛАЙДЫР ИНДЕ УЛ... Сабырлык – иң беренче урындадыр. Бу гаиләдә дә мөһим. Кирәк чакта эндәшмичә кала белергә кирәк.

ТАГЫН БЕР СЫЙФАТ – ТЫЙНАКЛЫК. Бу кием-салымда да, хисләрне белдерүдә дә, кеше белән аралашуда да чагылырга тиеш. Динебездә дә сабырлыкка күп урын бирелә.

ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫ ИРЕН БЕРЕНЧЕ УРЫНГА КУЯРГА ТИЕШ. Ир-ат өендә үзен хуҗа итеп тойсын. Андый хисне тойган ир-атка өенә кайту да рәхәт булачак.

ХАТЫН-КЫЗ ҮЗЕН НИЧЕК ТОТАРГА ТИЕШ? КОРЪӘНДӘ ӘЗЕР ИНСТРУКЦИЯ БАР.

Хәзерге заман хатын-кызы үзенә **БИК ЗУР ҖАВАПЛЫЛЫК АЛЫРГА ЯРАТА.** Бөтен дөньяга гаиләдәгесен чыгарырга да күп сорамый. Бу бик үк матур түгел, әлбәттә. Эш дип, акча дип, ирне, балаларны арткы планга күчерергә ярамый. Әйе, мондый хатын-кызны данлыйлар, аның турында сөйлиләрдер, әмма...

ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЫНА ШУНДЫЙ КИҢӘШ БИРЕР ИДЕМ: САБЫР ҺӘМ ТЫЙНАК БУЛЫРГА. Үз-үзеңне югалтмаска! Татар хатын-кызы – үзенең тыйнаклыгы белән башкаларга өлге дә. «Идентичность» дигән төшенчә бар. Без, хатын-кыз буларак та, моны онытырга тиеш түгел.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Видео: Лилия ГЫЙМАЗОВА

3 апрель | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
10.40, 17.10 «ХЫЯЛ = МАКСАТ» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00, 00.25 «Жырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30 «Галәм илчесеннән хәбәрбар» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТАКСИ ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Виктор науки» 12+
01.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
09.55 О самом главном 12+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «НЕУКРОТИМАЯ НЕУПОКОЕВА» 16+
23.30 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
07.00, 10.05, 13.55, 15.45, 04.00 Новости 0+
07.05, 22.30, 01.00 Все на Матч!
10.10, 15.25 Специальный репортаж 12+
10.30 «Вид сверху» 12+
11.00 Лыжные гонки. ФосАгро Кубок России
14.00 «Есть тема!»
15.50 Футбол. «Урал» – «Локомотив». FONBET Кубок России
18.00 Футбол. «Балтика» – ЦСКА. FONBET Кубок России
20.15 Футбол. «Спартак» – «Зенит». FONBET Кубок России
23.00 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 3
01.30 «Вы это видели» 12+
02.30 «Якушин. Первый среди первых» 12+
03.30 «История Хуана Мануэля Фанхио» 12+
04.05 Дзюдо. Турнир «Большого шлема» 12+

НТВ

04.55 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЧЕРНОЕ СОЛНЦЕ» 16+
22.15 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» 16+
02.45 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15, 04.25 Давай разведёмся! 16+
08.15, 02.45 Тест на отцовство 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.25 «Порча» 16+
12.55, 01.25 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «СУДЬБА НА ДВОИХ» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.25 По делам несовершеннолетних 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 19.55 «По горячим следам» 16+
11.20, 01.01 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ» 12+
13.40, 04.00 «РАЗВЕДЧИКИ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Лучшие самолеты Сухого» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ГОЛУБЫЕ ДОРОГИ» 12+
03.15 «Отечественное стрелковое оружие» 16+

4 апрель | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
10.40, 17.10 «ХЫЯЛ = МАКСАТ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ИСЕМЕМ ЦЗЮНЬ ЦЗЮ ЛИН» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Точка опоры» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Наши герои» 16+
23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Башваткыч» 12+
01.15 «Жырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ТАКСИ ПОД ПРИКРЫТИЕМ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
09.55 О самом главном 12+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «НЕУКРОТИМАЯ НЕУПОКОЕВА» 16+
23.30 Вечер с Владимиром Соловьёвым 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 08.30, 13.55, 15.45, 04.00 Новости 0+
07.05, 15.50, 18.45, 21.30, 00.30 Все на Матч!
08.35 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России 0+
14.00 «Есть тема!»
15.25 Специальный репортаж 12+
16.25 «Большой хоккей» 12+
16.55 Мини-футбол. «Синара» – «Ухта». Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига
19.15 Футбол. «Ахмат» – «Оренбург». FONBET Кубок России
22.30 Профессиональный бокс. А. Мазур – Л. Джафет. Олимпбет. Путь чемпиона
01.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
01.30 Баскетбол. «Пари Нижний Новгород» – «Уралмаш». Единая лига ВТБ 6+
03.30 «История Хуана Мануэля Фанхио» 12+
04.05 Дартс. OLIMPBET Международная лига. Тур 3 0+

НТВ

04.55 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЧЕРНОЕ СОЛНЦЕ» 16+
22.15 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» 16+
0.55 «Поздняков» 16+
01.10 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.10 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
02.40 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15, 04.35 Давай разведёмся! 16+
08.15, 02.55 Тест на отцовство 16+
10.30, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.35 «Порча» 16+
12.55, 01.35 «Знахарка» 16+
13.30, 02.05 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.30 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «КОНТРОЛЬНАЯ ДЛЯ ВЗРОСЛЫХ» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.35 По делам несовершеннолетних 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ» 12+
13.25 «ТАНКИСТ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Лучшие самолеты Сухого» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «НЕПОДСУДЕН» 12+
02.35 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ…» 12+
04.00 «Отечественное стрелковое оружие» 16+
04.40 «Победоносцы» 16+

5 апрель | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
10.40, 17.10 «ХЫЯЛ = МАКСАТ» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Җомга вәгазе». "Ярдәм" мәчетеннән турыдан-туры трансляция 0+
13.00, 00.40 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 00.00 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «НЕВЕСТА МОЕГО ДРУГА» 16+
00.25 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.35 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Жырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 2.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
9.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
09.55 О самом главном 12+
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 Прямой эфир 16+
21.30 «Удивительные люди» 12+
23.55 «Истории Большой Страны» 12+
00.55 «УДАР ЗОДИАКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Кто кого?» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 08.10, 15.25 Новости 0+
07.05, 23.30 Все на Матч!
08.15 Небесная грация 0+
08.35 Биатлон. Альфа-Банк Чемпионат России
10.50 Лыжные гонки. ФосАгро Кубок России
14.40 Футбол. FONBET Кубок России. Обзор 6+
15.30 Смешанные единоборства. One FC
19.25 Баскетбол. «Зенит» – УНИКС. Единая лига ВТБ
21.25 Футбол. «Айнтрахт» – «Вердер». Чемпионат Германии
00.30 «РецепТура» 6+
01.00 Баскетбол. «ПАРМА» – «Локомотив-Кубань». Единая лига ВТБ 6+
03.00 Смешанные единоборства. One FC

НТВ

04.55 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ЧЕРНОЕ СОЛНЦЕ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
02.10 «Квартирный вопрос» 0+
03.05 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.25, 05.00 Давай разведёмся! 16+
08.25, 03.20 Тест на отцовство 16+
10.40, 23.50 «Понять. Простить» 16+
11.45, 01.00 «Порча» 16+
12.55, 02.00 «Знахарка» 16+
13.30, 02.25 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «КАК СПАСТИ ВЛЮБЛЁННУЮ ЖЕНЩИНУ» 16+
23.20 Уютное утро 16+
05.50 «6 кадров» 16+
06.10 «ВЫБИРАЯ СЕБЯ» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «ТАНКИСТ» 16+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
9.20 «Ищу своих» 12+
10.10, 21.20 «Специальный репортаж» 16+
10.25 «По горячим следам» 16+
10.45 «БЕРЕГ» 12+
14.20 «Диверсанты» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 Д/с «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 Музыка+ 12+
00.55 «ДВОЙНОЙ КАПКАН» 16+
03.10 «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» 12+
04.50 «Хроника Победы» 16+

6 апрель | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.30, 01.15 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2024» 6+
15.00 «Рифат Зарипов – 35!» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «КАНИКУЛЫ ДЖОЙ» 12+
23.35 «НУ, ЗДРАВСТВУЙ, ОКСАНА СОКОЛОВА!» 16+
01.40 «АК ЧӘЧӘКЛӘР» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Зәңгәр кыңгыраулар» 16+
07.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.05 Гөлнара Тимерҗанова концерты 16+
14.40 «Шаян хәлләр» 16+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 Рифат Зарипов концерты 16+
23.20 Г. Исхакый. «Курчак туе». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.30 «Җырларым – хыялларым минем» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «СОБАЧЬЕ СЕРДЦЕ» 12+
15.50 «БАНЯ, ВОДКА, ГАРМОНЬ, ГОЛЛИВУД» 16+
17.00 «Я люблю мою страну» 0+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Эксклюзив» 16+
19.10 «Владимир Жириновский. Прямая речь» 12+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «КВН» 16+
23.50 «Эннио. Маэстро» 16+
02.40 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 Утро России. Суббота
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЖИЗНЬ СПРАВОК НЕ ДАЁТ» 16+
00.40 «КРЫЛЬЯ ПЕГАСА» 12+
04.00 «ПРИМЕТА НА СЧАСТЬЕ» 16+

МАТЧ ТВ

07.00, 10.05, 13.00, 15.45, 19.00, 04.00 Новости 0+
07.05, 13.05, 15.50, 19.05, 22.00 Все на Матч!
10.10 «ВОИН» 12+
11.55 Смешанные единоборства. UFC 16+
13.55 Мини-футбол. КПРФ – «Тюмень». Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига
16.25 Футбол. «Хайденхайм» – «Бавария». Чемпионат Германии
18.30 Футбол. «Журнал Лиги чемпионов» 6+
19.45 Футбол. «Ростов» – «Сочи». МИР РПЛ
22.45 Футбол. «Атлетик» – «Мальорка». Кубок Испании
01.15 Смешанные единоборства. UFC
04.05 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. 6+

НТВ

04.50 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.20 «Жди меня» 12+
07.20 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Секрет на миллион» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 ЧП. Расследование 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Звезды» 16+
23.00 «Международная пилорама» 18+
23.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.25 «Квартирник НТВ у Маргулиса» 16+
01.50 «Дачный ответ» 0+
2.45 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.55 Уютное утро 16+
10.25 «ДВА КРЫЛА» 16+
14.45 «СКОЛЬКО СТОИТ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.05, 06.00 «ВЕНЕЦ ТВОРЕНИЯ» 16+
02.50 «Преступления страсти» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «БОЛЬШОЕ КОСМИЧЕСКОЕ ПУТЕШЕСТВИЕ» 6+
06.25 «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 6+
07.55 «Морской бой» 6+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.20, 15.30 «Специальный репортаж» 16+
09.30, 03.30 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
11.10 Мужики 16+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды науки» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10 «Поколение смелых» 16+
15.50 «УЗНИК ЗАМКА ИФ» 12+
21.15 Всероссийский вокальный конкурс «Звезда-2024» 6+
22.30 «УСНУВШИЙ ПАССАЖИР» 16+
00.15 «ПРИКАЗ: ОГОНЬ НЕ ОТКРЫВАТЬ» 12+
01.55 «ПРИКАЗ: ПЕРЕЙТИ ГРАНИЦУ» 12+
04.55 «Москва – фронту» 16+

7 апрель | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.40 Илсөя Бәдретдинова концерты 16+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильм 6+
08.45 «Полосатая зебра» 6+
09.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Тархан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Погружение на 100» 12+
13.15 «Әдәби хәзинә» 6+
13.40 «Татар сүзе» 12+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2024» 6+
15.00 «Наша Республика – наше дело» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
22.00 «Семь дней» 16+
23.00 «МИЛЫЙ ДРУГ ДАВНО ЗАБЫТЫХ ЛЕТ» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Яшьлек дәрте яши йөрәгемдә» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Түгәрәк бәхет» 16+
16.05 «Татар сүзе» 12+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.50 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 М. Гыйләҗев. «Баскетболист». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 Играй, гармонь любимая! 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 «Жизнь других» 12+
12.15 «Повара на колесах» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.30 «ВОР» 16+
16.25 «Лучше всех!» 0+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Большая история» 16+
21.00 «Время»
23.00 «Что? Где? Когда?» 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.10, 01.05 «ЗЛАЯ ШУТКА» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
11.40 «Большие перемены»
12.40 «ЗДРАВСТВУЙ, СЕСТРА» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым 12+

МАТЧ ТВ

06.00 География спорта 12+
06.30 Футбол. «Журнал Лиги чемпионов» 6+
07.00, 09.30, 12.00, 15.45, 04.00 Новости 0+
07.05, 12.05, 15.50, 00.45 Все на Матч!
09.35, 04.05 Лыжные гонки. ФосАгро Кубок России
12.55 Баскетбол. «Енисей» – ЦСКА. Единая лига ВТБ
14.55 «Вы это видели» 12+
16.15 Футбол. МИР РПЛ
18.30 Футбол. «Динамо» – «Спартак». МИР РПЛ
21.25 Футбол. «Галатасарай» – «Фенербахче». Суперкубок Турции
23.45 «После футбола» с Георгием Черданцевым
01.30 Баскетбол. «МИНСК» – «Пари Нижний Новгород». Единая лига ВТБ 6+
03.30 Фрирайд. Мировой тур 6+

НТВ

04.55 «ЛЕГАВЫЙ» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.35 «Основано на реальных событиях» 16+
03.05 «МЕЧ» 16+

ДОМАШНИЙ

09.50 Пять ужинов 16+
10.05 «ЗОНТИК ДЛЯ ПОДРУГ» 16+
14.40 «Я ТЕБЯ НАШЛА» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.40 «ВЫБИРАЯ СЕБЯ» 16+
03.10 «Преступления страсти» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ГОЛУБЫЕ ДОРОГИ» 12+
06.50 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
11.10 «Легенды армии» 12+
12.00 «Моторы и колеса» 12+
12.50 «Война миров» 16+
13.40 «Код доступа» 12+
14.30 «Улика из прошлого» 16+
15.20 «Скрытые угрозы» 16+
16.10 «Секретные материалы» 16+
17.05 «Загадки века» 12+
18.00 «Главное» 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
22.10 Десять мгновений 12+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «БЕРЕГ» 12+
02.25 «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 6+
03.45 «ДИВЕРСАНТЫ» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Театр сәнгатен үстерүгә мөһим өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлекләре өчен «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе драма артисты – сәхнә остасы **Галицкий** Михаил Олегович, «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе баш рәссамы **Патраков** Александр Михайлович, республикада кинематографияне үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен кинооператор, «Россия Федерациясе кинематографиячеләр берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Гвоздь** Юрий Константинович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Мәгъдән булмаган материаллар заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Егоров** Валерий Михайлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе вице-президенты **Тимерханов** Айнур Әхәт улы, республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен **Миннәхмәтов** Минәхтәм Минсәгыйть улы, җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе **Галиев** Рәис Миншакир улы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Җәзаларны үтәү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе матди-техник һәм хәрби тәэминат базасы» федераль казна учреждениесе башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Колбасин** Александр Борисович, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының матди-техник тәэминат һәм дәүләт заказы бүлеге башлыгы **Таһирова** Флюра Гарәфетдин кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең кыллы халык уен кораллары кафедрасы профессоры, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Халык уен кораллары дәүләт оркестры артисты **Мөхәммәтдинова** Гүзәл Фаил кызына, «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Шакирҗанова** Гүзәл Рәшит кызына **«Татарстан Республикасының Халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәренең балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең саксофон классы буенча укытучысы **Бенько** Юрий Владимировичка, Казан шәһәренең «8 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Бобкова** Ирина Николаевнага, Казан шәһәренең «14 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең домра классы буенча укытучысы **Занько** Татьяна Александровнага, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «32 номерлы гомуми үсеш төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең музыкаль җитәкчесе **Киселева** Светлана Васильевнага, Казан шәһәренең «8 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең теория дисциплиналары һәм гомуми фортепиано укытучысы **Сафина** Луиза Шамил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Сәмил» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Гыйматдинова** Гөлсинә Нәфыйк кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

«ИҢ АВЫРЫ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ»

Фронттан: «Мин исән-сау, бар да яхшы», – дип килеп ирешкән сүзләрнең бәһасе алтын-көмешкә тиң икәнлеген газизен көтүчеләр генә аңлыйдыр. Әгәр ике арадагы җеп өзелсә, нишләргә? Фронт сызыгына барып, хәбәрсез югалган егетләрне эзләп табучы, һәлак булганнарны яу кырыннан алып чыгарга, туганнарына тапшырырга ярдәм итүче «Улзытон» төркеме җитәкчесе, активист һәм волонтер Сергей НИКИТИН белән көтү һәм өмет турында сөйләштек.

:: Сергей Николаевич, бу җаваплы эшкә ничек алынуыгыз турында сөйләгез әле.

– Бу эшкә ничек тотынуымны үзем дә сизми калдым. Мин озак еллар Чаллыда яшәп, эшмәкәрлек белән шөгыльләнгәннән соң, ял итәргә дип, Пойкино авылына яшәргә кайткан идем, ләкин тормышның планнары миңа карата башкачарак булган икән. Беркөнне туган тиешле кешебез, шалтыратып, улының Украинада һәлак булуын әйтте. Солдатны эзләп Луганскига киттек. Элеккеге эшемә бәйле рәвештә бөтен Россиядә танышларым күп. Бер шалтырату җитте – солдатның гәүдәсен яу кырыннан алып чыктылар. Күпмедер вакыттан соң тагын бер әни мөрәҗәгать итте. Анысы да ерак туганыбыз булып чыкты. Әти-әнисе белән барып, егетне Ростовтан табып алып кайттык. Дөресен әйткәндә, авыр эшкә баш-аягым белән чумасым килмәгән иде. Башта туганнар, танышлар дип баш тартырга кыенсындым. Хәзер инде мөрәҗәгать итүчеләрне туктата торган түгел, хәер, үзем дә бу халәтемне кабул иттем инде. Махсус рәвештә игъланнар да, телефон номерымны да калдырганым юк. Мине гадәттә «сарафан радиосы» аша эзләп табалар.

:: Әлеге вакытта якынча ничә солдатны туганнарына алып кайтып тапшырдыгыз?

– Мин аларны санап бару яклы түгелмен. 1–1,5 ел эчендә якынча 300ләп хәрбине туган якларына кайтарырга ярдәм иттек. Монда исәннәр дә, үлгәннәр дә бар. Ә мөрәҗәгатьләр бермәбер күбрәк. Тоткынлыкка эләккән егетләрне дә чыгарырга ярдәм иткән булды. Алары – аерым бер тарих.

:: Ә сезгә бу эштә кемнәр булыша?

– Ярдәмчеләрем – бөтен Россия буйлап таралган, эвакуация командасындагы егетләр. Күп очракта шундагы егетләр булыша. Минем бөтен фронт буенча танышларым бар. Үзләренә дә ничек булдыра алам, шулай ярдәм итәм. Гуманитар ярдәм алып барам да хәбәрсез югалган егетләрне эзлим. Берничә тапкыр эвакуацион команда белән бәрелешләр барган җиргә керергә дә туры килде. Һәлак булган егетләрне иптәшләренә алып чыгу бик авыр. Бик теләсәләр дә, алар аны күп очракта эшли алмый. Үзләрен дә саклыйсылары бар бит. Хәбәрсез югалган солдат клиникага эләккән булса, шактый тиз табыла. Бик озак табылмый икән, гадәттә, ул исән түгел булып чыга. Хәтерен югалтучылар да, комада ятучылар да, качаклар да бар. Кызганыч, элемтәгә чыкмаганнарның күпчелеге һәлак булган булып чыга. Югалганнар арасында йөзнең унысына гына бәхет елмаерга мөмкин. Әле менә яңа гына бер егет исән килеш табылган, дип хәбәр иттеләр. Аның әти-әнисе дә юк, әбисе дә авыру. Гомере бетмәгәч, исән-имин табылды менә. Егет өчен бик сөендем. Минем төп эшем – югалган солдатны эзләп табу, яу кырыннан юллап алып чыгу һәм Ростовтагы клиник хастаханәгә хәбәр итү. Калганы – туганнарына җиткерү, алар белән эшләү, җәсаден алып кайту, җирләү – рәсми органнар эше. Хәер, берничә тапкыр солдатларны госпитальләрдән үзебезнең дә алып кайтканыбыз бар.

:: Сезнең төп эшегез фронт сызыгында бара, димәк?

– Юк, минем эшем бер генә көнгә дә туктап тормый. Менә күрәсезме боларны (Сергей Никитин үзе белән алып килгән калын ике папкага төртеп күрсәтте. – **Авт.**)? Аларда – югалган һәр солдат буенча бөртекләп җыелган мәгълүмат, минем төрле урыннарга язган хатлар. Ә фронт сызыгына мин монда башкарылган хезмәткә соңгы ноктаны куярга барам. Сугыштагы егетләр шикелле үк, безгә дә куркыныч яный. Һәлак булган солдатны эзләп, берничә мең чакрым юл узарга туры килә. Элек куркыта иде, хәзер ияләштем инде. Беренче эзләп тапкан солдатның гәүдәсе әле дә күз алдында.

:: Бу эштә иң авыры нәрсә?

– Иң авыры – әниләр белән сөйләшү. Алар белән сөйләшкәнче мин дошман уты астында егетләрне эзлим, дим. Шуңа күрә мин әниләренә, хатыннарына якыннарының һәлак булуы турында бервакытта да хәбәр итмим. Аларның һәркайсы соңгы минутка кадәр өмет белән яши бит.

Берничә ай дәвамында баласыннан зарыгып бер хәбәр көткән ана акча турында уйламый, алар шул дәрәҗәгә килеп җитә ки, баласының гәүдәсен кайтарып җиткергән өчен дә башын иеп рәхмәт әйтә. Ничек шундый әниләргә ярдәм итмисең инде?!

Кызганыч, яшь хатын-кызлар арасында җәсаденнән бигрәк, солдатның акчасын гына көтүчеләр дә бар. Әле берничә көн элек кенә: «Гәүдәсе кирәкми, акчасы булса, шул җиткән», – дигән сүзләрне ишеткәч, хәрбине эзләүгә киткән никадәр вакытымны кызгандым. Мин ул вакытны һәм энергияне балалары өчен җанын бирергә әзер булырдай аналарга багышлар идем. Тәҗрибә белән андыйларны тоемлый башладым инде. Кайберәүләр шалтырата да: «Син ничә сум акча сорыйсың?» – диләр. «Мин такта сатаммыни? Яки берәр оешманың директорымы?» – дип җавап бирәм. Акчаны сорап алмыйм. Әти-әнисенең көченнән күпме килә, шуның кадәр бирәләр. Әле ярый Мамадыш башлыгы Анатолий Петрович булыша.

Сергей Никитинның шәхси архивыннан

Сергей Никитинның ярдәмчеләре бөтен Россия буйлап таралган.

:: Сезнең кебек оешмалар республикада тагын бармы?

– Без – шул урыннарга барып, фронт сызыгы буйлап йөреп егетләрне эзли торган бердәнбер оешма. Россиядә безнең кебекләр башка юк. Баштарак бөтен ил буйлап мөрәҗәгатьләрне кабул итә идек, хәзер Татарстан белән Удмуртия егетләрен генә эзлибез, чөнки барысына да өлгереп булмый. Февраль ахырында Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында хисап-сайлау конференциясе булды. Анда Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты. Шушы эшебезне тагын да җәелдерүне теләп, аңа мөрәҗәгать иттем. Игътибарсыз калдырмады, башкасын киләчәк күрсәтер. Мин үзебезнең колл-центр булуын телим. Әлегә барлык рәсми хатларны, документларны үзем генә алып барам, мәгълүматларны туплыйм. Әгәр бу эшләрнең бер өлешен кызлар да башкарырга булышса, мөмкинлекләр күбрәк булыр иде.

:: Сергей Николаевич, иң төп сорау: якыныннан хәбәр килми башлаган кешегә нинди киңәш бирәсез?

– Якыннары хәбәрсез югалганнарның иң зур хаталары – шунда ук паникага бирелү. Эшне зур түрәләргә, җитәкчеләр, военкомат, прокуратурага шалтыратудан башламаска киңәш итәр идем. Баласы, ире белән бергә булган иптәшләрен табып шалтырату күпкә нәтиҗәлерәк булачак. Соңгы хәрби боерыкны үтәү өчен аның белән бергә кергән егетләргә яисә алар белән элемтәдә торган туганнарына чыгарга, язарга кирәк. Шуңа күрә хәрби кайда, кемнәр белән хезмәт итә, позывноен, полк, батальон, рота, взводын, жетон номерын алдан ук белешеп кую файдалы булачак.

Нәтиҗә булсын өчен, күпмедер вакыт көтеп торудан мәгънә юк дип уйлыйм. Әгәр кеше даими рәвештә хәбәрдә булып, соңгы заданиедан соң элемтәгә чыкмый башлаган икән, димәк, ул югалган. Вакытны сузмыйча аны эзли башларга кирәк. Шашыр дәрәҗәгә җитеп эзләү турында сүз бармый. Тыныч, аек акыл белән эш итү файдалырак булачак. Ягъни элемтә өзелүгә үк тыныч кына белешә башларга кирәк. Бергә хезмәт иткән иптәшләреннән соң военкоматка мөрәҗәгать итәргә, анда алган мәгълүматлар белән частьның, ротаның яки взводның командиры белән элемтәгә чыгарга була. Шуннан соң гына хәрби прокуратурага барырга кирәк.

Багучылар, кәрт ачучыларга да барырга, кешеләрне эзләүче ышанычсыз фондларга керергә, мәгълүматлар сатып алырга, акча да күчерергә кирәкми. Аларның күпчелегендә мошенниклар, акча кортлары гына утыра.

Аннан соң андый вакытта имеш-мимеш, кеше сүзләренә дә артык игътибар бирергә кирәкми. Бары тик мөһер сугылган документка гына ышанырга кирәк.

:: Шулай да шушындый катлаулы, рухи һәм физик яктан күп көч таләп итә торган эшкә алынуыгызга тора-тора үкенгәнегез булмадымы?

– Мөмкинлегем, саулыгым булганда, әти-әниләргә ярдәм итәргә тырышачакмын. Фронттан кайткан егетләр: «Без сугышканда, син, сау-сәламәт ир, монда нәрсә эшләдең?» – дип сорагач, оят булмасын өчен. Үзем дә китәр идем, ләкин минем биш балам бар. Кечкенәсенә 2 генә яшь. Талпынып алам да, хатын: «Син балаларыңны кемгә калдырасың?» – дигәч, уйга калам. Минем әни гомер буе укытучы булып эшләде, кешеләргә ярдәм итте. Үзем дә авылда часовня төзедем. Авыр, куркыныч юлларда мине шул изге эшем саклап йөртәдер, дип уйлыйм. Минем өчен мәчет белән чиркәү арасында аерма юк. Аллаһ – бер. Теләсә кайсы хәрбидән сорасагыз, алар үзләрен Аллаһы Тәгалә генә саклап калды диячәк. Хәтта атеистлар да яу кырында Аңа ышана, дога кыла башлый. Мин моны төгәл беләм.

Зәһрә САДЫЙКОВА

ХАҖИЛАР АВЫЛЫ

Теләче районының йөздән артык йорты булган Иске Җөри авылында 20гә якын кеше (!) хаҗи. Кече хаҗга (гомрә) баручылар да бар. Иң яше – 12 яшьлек Билал. Рухи яктан үзгәргән авылда без дә булып кайттык.

«Дөнья малы – икенче урында». Авыл халкы белән аралашканда шушы сүзне еш ишетергә туры килде. Яше дә, карты да әйтә моны. Хаҗга бару күпләрнең тормышын үзгәрткән. Әйтик, Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиевкә изге җиргә 10 мәртәбә барырга насыйп булган.

Мөхәммәт – имам, Алсу – абыстай. Ирле-хатынлы Фәләхиевләр авылга иман нуры өләшә. Алар да хаҗ кылулары белән бәхетле. Мөхәммәт 16 яшьлек кызы Зөбәйдә белән мәчеттә дини гыйлем бирә. Балалар Коръән ятлау ярышларында район, республика күләмендә беренче урыннарны ала. Урамда русча сөйләшүчеләр күренми. Бакча һәм мәктәптә татарча белем һәм тәрбия бирелә. Авылда эчү дигән нәрсә юк диярлек. Салып йөрүчеләр берән-сәрән генә. Туйларда да, Сабантуйда да хәмер эчмиләр. Һәрхәлдә, авыл халкы шулай диде. Өч кибетләренең берсе – хәләл. Без кергән кибеттә сатучы мөселман кызы азан тыңлый иде. Тик киштәләрдәге аракы шешәләре генә күңелне кырды. Монысы инде аннан гына тормый.

– Дөньялыкны беренче урынга куймыйбыз. Без бу тормышта кунак кына. Күбрәк ахирәт турында уйлап яшибез. Күреп торасыз, өебез дә тыйнак. Ишекләрне үзем ясаган идем. Искерсә дә, алыштырмыйбыз. Байлыкка ис китми. Булганына шөкер итәбез. Көнебезне гыйбадәт кылып үткәрергә тырышабыз. 2009 елда хаҗ кылдым. Кечкенәдән күңелдә бар иде бу теләк. 10 яшьтән бүгенгә кадәр уразаны калдырмыйм. Диннән ерак кеше түгел мин, – ди 68 яшьлек Рәис абый Дәүләтшин.

Авыл халкы иманның артуын мәдрәсә ачуга бәйләп аңлата. Заманында шушы авыл кияве Фидаил Яруллин төзеткән аны. Гарәбстанда белем алгач, авылда йорт, мәдрәсә салып, хатыны Әлфия белән халыкка дини белем биргән алар. Хәзер Казанда яшиләр икән. «Әгәр авылда яшәвен дәвам итсә, Иске Җөридә һәркем гарәпчә сөйләшкән булыр иде», – диючеләр дә очрады.

Зөлфия Хәлиуллина

«Хаҗ кылу – иң зур бәхет», – ди Светлана Ибраһимова.

Светлана Ибраһимова Карашырмә авылында башлангыч сыйныф укучыларын укыта. Кечкенәдән дини тәрбия алган. Дәү әнисе абыстай булган. Ибраһимовларның балалары да – дин юлында. Әдәп, әхлак буыннан-буынга күчеп килә шулай.

– Ирем 2006 елда бер мәртәбә хаҗ кылган иде инде. Тагын биш елдан бергәләп барырга насыйп булды. Мөмкинлеге булган мөселман хаҗга барырга тиеш, – ди ул. – Акча җыйдык та тәвәккәлләдек. Ул вакытта бәясе дә артык кыйммәт түгел иде әле. Хәзер 500 мең сумнан күбрәк акча кирәк. Авыл халкының артык байлыгы юк. Әмма хәзер тормыш күпкә яхшырак. Терлек асрап көн күрәбез. Барысын да хәләл көч белән табарга тырышабыз. Бәрәкәте булсын, – ди Светлана Ибраһимова.

Казандагы тернәкләндерү үзәге директоры Мәликә Гыйльметдинованы әлеге авыл үзенә әхлагы, иманы белән җәлеп иткән. Сүз уңаеннан, ул да биш тапкыр хаҗда булып кайткан. Моннан ун ел элек авылда ятимнәр йорты ачканда, беренче чиратта рух, әхлак, тел, ләгать кебек төшенчәләргә игътибар иткән. Бар да канәгатьләндергән! Мәликә ханым әлеге приютны «Гаилә учагы» дип йөртә. Ятимнәр дип әйткәнне бер дә яратмый. «Бу – минем гаилә», – ди. Анда берьюлы 13 авыру баланы сыендырган ул. Һәммәсе дә «әнием» дип дәшә икән. Ул чакта иң кечкенәсенә 2 яшь кенә була әле. Балалар инде үскән: кайсы гаилә корган, кайсы белем ала. Хәзерге вакытта приютта дүрт бала тәрбияләнә.

– Иске Җөрине Изге Җөри дип үзгәртер идем. Мин – шәһәр кызы. Кайларда гына йөрмәдем, әмма әлеге авылдагы кебек җылы мохитне беркайда да тоймадым. Кешеләре бик әйбәт. Алар туганнарыма әйләнеп бетте инде. Хәзерге вакытта шәһәрдә яшәсәм дә, авылга еш кайтып йөрим. Балалар белән бергә җыелышабыз. Үзебезнең традицияләребез бар, – ди Мәликә Гыйльметдинова. – Сигез төрле миллəттән алар. Татар бакчасына, мәктәбенә йөргәч, татарчаны яхшы беләләр. Бу да – авылның балаларга биргән байлыгы.

Сәрия МИФТАХОВА

«ҖӘЙ МАТУР БУЛЫР»

Яз кояшы күзне иркәли башлады инде. Әкренләп тау битләрендә кар эри, күңелне күтәреп, сыерчыклар сайрый. Чын яз кайчан килер? Җәй нинди булыр? Без бу хакта редакциянең якын дусты, Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче халык синоптигы Әмир ШӘРӘФИЕВ белән сөйләштек.

Ул яшерми, кайчак сынамышлар да сыната. Синоптик сүзләренчә, 99 елдан соң һава торышы төгәл кабатлана икән. Ә менә 33 елдан соң шактый өлеше туры килә. 11 елдан соң ел елга бераз охшап килә. Әмма соңгы елда язның – язга, кышның кышка охшап килүе аны бик сөендергән.

– Карга бураннары узды инде. Ә сыерчыкнык көтәбез әле. Узган ел ул бик сизелерлек булмады. Әзрәк кар очты да шуның белән бетте. Мин каргаларны 26 февраль көнне күрдем инде, – ди Әмир абый. – Әкренләп табигать уяна башлады. Кара каргалар да көн җылытасын белде, оя кора башладылар. Алар бит көннәр җылытмыйча йомырка да салмый. Кара каргаларны 4 мартта берән-сәрән күргән идем. 14 мартта төркемнәре белән килделәр. Узган ел алар 19 февральдә килгән булган. Хәер, хәзер бит каргалар ерак китми. Кыш җылы килгән елларны китеп тә тормыйлар иде. Алар барысын белеп тора. Кошларны күзәтеп, без өйрәнәбез.

Язгы ташуга килгәндә, ул үз фикерендә: куркыныч янамый.

– Кар күп яуган елны туң булмый. Быел да шулай бит. Никадәр кар яуган иде, инде әкренләп җиргә сеңеп бара. Тик яз тиз генә килергә ашыкмый әле ул. Бу көннәрдә кыш белән «сугышып» яткан мәлләре. Әмма яз үзенекен итә, ял көнне чын яз киләчәк. Ныклап җылыта башлый, – ди синоптик. – Елгалар тиз генә ачылмас әле. Вак сулыкларда апрель урталарында су күтәрелсә, эре елгаларда 24ләре генә боз китәр, дип уйлыйм. Чулман, Нократ елгалары майның унбишләрендә генә ташыячак.

Әмир абый май башында көннәр җылытып җибәреп, июньнең беренче атналарында эссе булыр, дип фаразлый. Шул чорда авыл хуҗалыгына зыян килмәсә ярый инде, дип борчыла.

– Туң булмавы үсемлекләр өчен әйбәт ул. Әмма май ахыры – июнь башларында көннәр коры булачак. Уҗымнарга дымның иң кирәк вакытында эссе комачау итәчәк. Әмма өмет бар. Җир асты сулары ярдәмгә килер, дим. Әлеге дә баягы карның күп булуы коткарыр кебек. Уҗымнар үрчер, дип уйлыйм, – ди Әмир абый.

Аның әйтүенчә, әгәр һава торышы шартлары уңай булса, шытып чыккан уҗым «балалый» икән, бер төптән берничәгә әйләнә. Болай үрчеп үсүе – билгеле, мул уңышка ишарә.

– Чәчү вакытында да, урып-җыюда да көннәр матур торыр. Җәй начар килер дип уйламыйм мин. Яңгыры да булыр, эссесе дә, – ди Әмир абый.

Татарстанның Гидрометеорология үзәгеннән алынган мәгълуматлар буенча, алдагы көннәрдә яуган кар һәм яңгырлар әкренләп бездән китеп бара. Республиканың көнбатыш өлешендә инде явым-төшем юк, ә

Идар Мөхәммәтҗанов

менә көньяк районнарда әлегә кар, буран күзәтелә. Якын көннәрдә Татарстанда явым-төшем көтелми. 29 март көнне төнлә һәм иртәнге якта томан төшәчәк. Һава температурасы төнлә –4…–9 градус булачак. Көндез исә +6 градуска хәтле җылытачак. 30 мартта төнлә 0…–5 градус, кайбер урыннарда –6…–11гә дә төшәчәк. Көндез +7 градуска кадәр җылыта. 31 мартта исә төнлә дә +3 градус җылы булачак. Көндез +8 булыр дип көтелә. Киләсе атна башында явым-төшем көтелми, +13 градуска кадәр җылытачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Гаилә архивыннан

КҮҢЕЛ БЕЛӘН ЯРАТУ

Арчада яшәүче Фирдәүсә ханымга олы йөрәкле тормыш иптәшен очратканчы урау юллар узарга туры килә.

Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүгә гидрометеорология техникумына укырга керә ул. Булачак ире белән дә шунда таныша. Башта бар да яхшы кебек тоела. Тик беренче балалары авыру булып тугач, гаиләдә җылылык бетә.

– Кызыма 3 ай чагында анда ДЦП икәнен, өстәвенә эпилепсия өянәге дә барлыгын белдек. Туганда имгәнгән, диделәр. Үз балаң нинди булса да, кадерле һәм газиз. Кызымны бик яратып карадым. Аннары тагын авырга уздым. Икенче балабыз – улым туды. Ирем белән мөнәсәбәтләр тагын да катлаулана барды. Ул кызымның авыруын кабул итә алмады. Өченче бәбием карынымда иде, ирем гаиләдән китте, – дип искә ала Фирдәүсә ханым.

Ярый ла әти-әнисе, туганнары гел янәшәдә була. Икенче баласы тугач, Арчага кайтып яши башлый алар. Фирдәүсә ханым бирешми – өч баласы хакына тормышның якасына ябыша.

Гаиләгә тагын күңелсез хәл килә. 2002 елда Тимур исемле кече улының өстенә капка төшә. Ул бик каты имгәнә. Биленнән алып аягына кадәр гипста була. Әмма сынауларга бирешергә өйрәнмәгән Фирдәүсә ханым бу юлы да көчле булып кала. Алар сынауны бергә җиңә. Уллары аякка баса.

Бервакыт Фирдәүсә ханымга кызы белән ял итәргә юллама бирәләр. Әниемне җибәрермен дип уйлап куя ул. Әллә ана йөрәге сизенә инде, әллә бераз ял итсен, дип санаторийга кызын җибәрә.

– Әнием куып диярлек озатты. Шул ял тормышымны үзгәртте дә куйды минем. Каршы яктагы бүлмәдә яшәүче Илгизәр белән таныштым. Дөресрәге, башта кызым белән дуслашты алар. Сабыем Илгизәрне күрсә, нишләргә белми иде. Сөйләшеп киттек. Мин үз язмышымны сөйләдем, Илгизәр – үзенекен. Миннән ун яшькә олырак, Апас районының Дәвеш авылыннан. Кечкенә вакытында өстенә агач төшеп, бер күзе сукырайган, икенчесенә зыян килгән, – дип сөйли Фирдәүсә ханым. – Илгизәр бик матур итеп баянда уйный. Ирсез тормыштан бик арыган идем инде. Илгизәр белән кушылгач, тормышым түгәрәкләнде. Мин үземне хатынкыз итеп тойдым.

Алар кызларын 26 яшенә кадәр карап үстерә. Ул моннан 8 ел элек вафат була.

– Илгизәр белән яши башлагач, уртак кызыбыз Гөлия туды. Аңа 20 яшь инде. Олы улым Данилгә – 30 яшь. Ул әле өйләнмәгән. Кече улыма – 29 яшь. Ул хатыны белән ике бала үстерә, – ди Фирдәүсә ханым. – Миңа түгел, Илгизәргә сокланырга кирәк. Мин аңа карап, үземдә яшәргә көч таба идем. Әле дә шулай. Инде икенче күзе дә бөтенләй күрми. Өч балалы, аның өстенә берсе урында гына ята торган сабый үстерүче хатын янынан сау-сәламәт ир качканда, Илгизәр мине ничек бар шулай кабул итте. Нинди йөрәге белән минем белән тормыш башларга риза булгандыр ул?! Мин аңа бик рәхмәтле. Ирем – бик матур, чибәр кеше. Күзләре күрмәү комачау итми. Аның белән бик рәхәт. Бәхетле булыр өчен күңел күзләре күрү дә җитә икән, дим мин. Сеңелләрем дә, безнең җизни кебек кеше юк, дип тора. Менә шуннан чамалагыз инде.

Фирдәүсә ханымнан беренче ире турында да сораштык. Арчага бер тапкыр кайтып килгән ул. Инде күптән вафат икән. «Әгәр тагын бер кат яшәсәгез, үз язмышыгызны узар идегезме?» – дим. Фирдәүсә апаның күңеле тулып китте. Күз яшьләрен сөрткәч, дәвам итте ул:

– Аллаһы Тәгалә, яраткан кешемне сынармын, дигән. Минем урында башка берәү, бәлки, бу сынауны уза да алмас иде. Янәшәмдә таяныр кешеләр булганга, мин авырлыкларны җиңә алдым. Илгизәрем терәк булды. Бүген мин бик бәхетле, – ди Фирдәүсә апа. – Әгәр гомер тагын бер бирелсә, тормыш юлымны кабат үтәр идем. Әмма кайсыдыр җирен дөресләп тә куяр идем. Һәркем үз юлын үзе үтә. Хаталарсыз кеше юктыр. Миндә дә бар алар. Әмма шунысын әйтә алам: кешеләрне рәнҗетмәдем, дөньяны яратып яшим…

Язылганга кире кайтып

ФӘНЗИЯ КАЮМОВА:

«БЕЛГӘННӘРЕМНЕ УКЫП, ҺӘР КЕШЕГӘ ДОГА КЫЛАМ»

Моннан 4 ел элек 26 яшьлек Тәлгать Каюмовның тәне бик каты пешеп, авыр хәлдә калганын язган идек. Янәшәдәге басуга чыгып, дуслары белән шашлык пешермәкче була алар. Учак ягам дигәндә генә егеткә ут каба. Ул чакта тәненең 80 проценты зыян күрде. Әнисе Фәнзия апаның да хәле авыр иде. Әмма алар бирешмәде, икәү бергә авырлыкны җиңеп чыга алдылар.

– Коронавирус башланган вакыт иде. Бер җирем авыртмаса да, миндә шул чирне таптылар. Әллә ничә кат тест бирдем. Шулай итеп, табиблар Тәлгать янынннан чыгарып җибәрде. Ә ул чакта балага минем ярдәмнең иң кирәк вакыты иде. Мин монда елап яттым, ул анда тилмерде. Бераздан миңа аның янына керергә рөхсәт иттеләр. Ни күрим, балам бик нык ябыккан, тиреләре начарланып беткән иде. Өйгә алып кайтырга куркам. Әнә шулай килеп-китеп 1 ел да 3 ай йөрдем, – дип искә ала Фәнзия апа. – Ул вакытта Тәлгатемнең сыйныфташларының әниләре бик ярдәм итте. Алар миңа, баланы бетерәсең, үз өстеңә алып, өеңә алып чык, диделәр. Башта бик курыктым. Кулымда бер тиен акчам юк. Гел улым янында булгач, эшли алмадым. Кешедән ничек акча сорыйм ди?! Тормышымның иң авыр вакытларында да кешедән әйбер сораганым булмады бит…

…Ире Рәфкать белән бик яратышып өйләнешә алар. Уллары туа. Тик матур гына яшәгәндә, ире юл фаҗигасенә очрый. Шуннан имгәнеп кала. Умырткалары сынып, аягына баса алмый.

– Ул чакта иремә 38 яшь иде. Табиблар хастаханәдән чыкканда озак тормас дигәннәр иде. Аллага шөкер, 8 ел яшәде. Язмыш сынавын бергә үттек. Әле ул чакта без иске баракта яши идек. Шәймиевкә рәхмәт, тузган бараклан 2003 елны безне ул күчерде. Озак елап утырып булмады, ялгызлыкны эш белән җиңдем мин, – ди Фәнзия апа. – Улым пешкәч, мин бөтенләй авыруга әйләндем. Кан басымым уйный башлады. Сәламәтлегем какшады. Үземне уйлаганым булмады, улым гына исән калсын, дип теләдем. Алып чыктык без аны өйгә. Улымның дусларының әти-әниләре безнең хәлне дөньяга чыгарды. Шуны ишетеп, иң беренче булып сез килеп яздыгыз бит. Әнә шуннан соң безгә бар дөнья ярдәм итә башлады. Әллә кайлардан шалтыратып хәл белделәр. 150шәр мең сум акча күчергән кешеләр булды. Улымның тәнендә ачык яралар булгач, чисталык та мөһим иде. Фатирыбызда ремонт юк иде. Ишекләребез иске иде. Барысын да хәл иттек. Улыма шартлар тудырдык. Хәтта телевизор алып биреп, Тәлгать карап ятарлык итеп куеп та киттеләр.

Фәнзия апа әле дә үзләренә ярдәм иткән һәр кешегә рәхмәтен укый. Шөкер, улы аягына баскан. Хәзер аны танып та булмый. Тазарып та киткән. Ике ел буе I группа инвалид булып йөргән, хәле яхшыргач, III группа инвалидлык бирәләр. Тик ул әле эшли алмый. Пешкән урыннары бик сызлый, ди.

– Улым кояшта да озак йөри алмый. Аллергиясе бар. Бик сызлана инде. Һава торышы бозыласы булса, төннәр буе йоклый алмый ята. Мин, өйлән инде, дип аптыратам, ә ул ашыкмый. Үз хәлен беләдер инде. Гаилә кору уен эш түгел. Җаваплылык сорый. Матди ягы да кирәк. Сәламәтлегеңне югалткач, кире кайтарып булмый, – ди Фәнзия апа. – Улым терелсен өчен хәләл акчаларын биргән һәркемгә көн саен дога кылам. Мин аны үзем генә берничек тә аякка бастыра алмас идем. Көнаралаш өебезгә табиб белән шәфкать туташы килеп йөрде. Аларга күпме акча түләдем. 6 ай буе бит бу! Безнең хакта сорашкан, әле дә хәлебезне белеп торган һәркемгә чиксез рәхмәт. Улымның дуслары, аларның әти-әниләре алдында баш иям. Иң зур рәхмәтем «Ватаным Татарстан» газетасы журналистына. Берәүгә дә мондый борчу-хәсрәт килмәсен.

Автор фотосы

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КЫЗЫК ТҮГЕЛ:

ТАТАРЧА ЮМОР ТУРЫНДА ҖИТДИ СӨЙЛӘШҮ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Түгәрәк өстәл»дә язучы-сатирик **Камил КӘРИМОВ,** язучы, юморист **Алмаз ХӘМЗИН**, журналист, «ВТ»да «Ха-ха-ханә» сәхифәсен алып баручы **Данил СӘФӘРОВ**, Татар КВН лигасы җитәкчесе, «Шалт, Мөхәммәтҗан!» проекты продюсеры **Рамил АГДЕЕВ**, сценарист, юморист **Фаил БАЯЗИТОВ** катнашты. Утырышны баш мөхәррир урынбасары **Гөлинә ГЫЙМАДОВА** һәм журналист **Лилия ГЫЙМАЗОВА** алып барды.

Татарча юморның бүгенге хәле турында

Алмаз ХӘМЗИН:

– Моннан якынча 700 еллар элек Хуҗа Насретдин булган, ә хәзер без үзебез Хуҗа Насретдин хәлендә. Бүгенге вазгыятькә, тормышка юмор күзлегеннән карамасаң, шактый авырга туры килә. Шул ук вакытта хәзерге юморга да шикле елмаю аша карасаң, дөресрәк булачак.

Тарихны искә алыйк. 1923 ел, Совет хакимиятенең ныгып кына маташкан чагы. Илдә – бардак, бөтен җирдә – аферистлар. Шул вакытта хөкүмәт «Чаян» журналы ачарга дигән карар кабул итә. Ни өчен кирәк ул аңа? Чөнки аңа ярдәмче кирәк.

Камил КӘРИМОВ:

– Ул заманда «Чаян» юморның бер бәллүр касәсе кебек булды, һәрбер матбугат чарасына да юмор бирү рөхсәт ителми иде. Хәзер юморны һәр матбугат чарасы бирә ала. Хәлдән килгәнчә тырышалар. Шуңа күрә «Чаян»ның икмәген дә алдылар кебек. Әйдәгез, алайса, сез дә матбугатта үрнәк күрсәтегез, гел «Чаян»ча гына булмасын. Мин шуны көтәм хәзер яшьләрдән.

Фаил БАЯЗИТОВ:

– Мин килешәм сезнең белән. Юмор матбугатта да актуаль булырга тиеш, һичшиксез. Ләкин бүген юморның тармаклары бик күп. Аның тамашачысы да киң һәм төрле. Бүген безгә замана тенденцияләре артыннан өлгерергә иде.

Камил КӘРИМОВ:
– Вагаеп бетте инде ул хәзер. Һәммәбезнең телефонда шул кыска диалогларны гына укырга вакытыбыз бар, ә зур әсәрләрне, повестьларны, сатирик хикәяләрне укымыйбыз. Сез, укый торганны язгыгыз, диярге мөмкинсез. Укымаган кеше әллә ниләр әйтә ала ул. Ләкин вагайды, чәчелде безнең бәллүр касә. Заманында Фатих Әмирхан, Шакир Мөхәммәтовлар зур-зур повестьлар язган. Халык авыр яшәгән, ләкин аңа юмор кирәк булган. Совет заманында да җиңел булмагандыр, ләкин сатира-юмор тәрбияләде халыкны. Миңа калса, хәзер тамак туйды, тормыш бөтен, безгә шул кикертә торган мәзәкләр генә кирәк.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Аның бит хәзер заманы башка. Бар нәрсәнең вакыты чикле. Көн буена телефоннан әллә никадәр әйбер укыйсың, әмма ул синең башыңа сеңми. Баш миебез чүп савытына әйләнде, килешәм.

Без үткәннәрне хөрмәт итәбез. Сез сөйләгән заманнар булмаса, бүгенге көн булмас иде. Ләкин без менә бүгенгә килеп җиттек. Әгәр хәзер тиз арада шушы заманны кабул итеп, балаларыбызны аңа туры китерә алмасак, киләчәгебез сорау астында калырга мөмкин.

Алмаз ХӘМЗИН:
– Хәзерге заман юморы, тәрбияләү мәсьәләсенә килгән вакытта да, урыс әйтмешли, «не соответствует».

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Әйе, юмор – халыкка ярдәмче дә, тәрбияче дә ул, җәмгыятьнең көзгесе дә ул, һәм шулай булырга тиеш тә. Ләкин хәзер ул көзгегә томан сиптеребрәк карарга кирәк. Туры бәреп ярамый.

Алмаз ХӘМЗИН:
– Туры бәрә белергә кирәк!

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Туры бәрә белү ул инде туры бәрү түгел. Дөрес ракурстан бәрергә кирәк. Ләкин, әйдәгез, бәхәсне туктатып, бераз ачыклык кертик. Сез заманча юморга бәя биргәндә, кемнәрне күз уңында тотасыз? Миңа кызык бит.

Камил КӘРИМОВ:
– Кемнеңдер исемен атамыйм. Ләкин тенденция нәрсәдә: һәр гаилә үз филармониясен оештырды хәзер. Ир белән хатын җырлый, балалары бии. Кеше автор белән эшләми. Үзе җыр яза, шуңа күрә «Мәйдан»ны ачсаң да, ТНВны ачсаң да, юмордан бигрәк, «И әнием, әнием, әнием» (әлбәттә, әни кеше – олы кеше) дип җырлыйлар. Ләкин бөтен җыр гаилә җыры була алмый. Юмор да шул хәлдә бүген. Шуңа күрә ул сәхнәгә чыга алмый.

Рамил АГДЕЕВ:

– Сезнең «Әйдә шаярт»ны караганыгыз бармы? Һич югы, андагы сәламләү бәйгеләрен. Сүз дә юк, командалар төрле, әмма араларында бик көчлеләре бар.

Камил КӘРИМОВ:
– Кабызам да үтеп кенә китәм.

Алмаз ХӘМЗИН:
– Бар-бар, мин бер жюрида да утырдым. Әле ул вакытта «более-менее» КВН иде. Ә хәзерге КВНыгыз бернәрсәгә ярамый.

Рамил АГДЕЕВ:
– Рәхмәт. Шуны беләсе килгән иде.

Камил КӘРИМОВ:
– Элек сәхнәдән тулы күләмле әсәрләр яңгырый иде. Хәзер бер сюжетка тезелгән мәзәк кенә... Әлбәттә, анысы да кирәктер. Аннан соң, тәрҗемә ителгән юморны тыңлап булмый. Ул мөмкин түгел. Татар үзенең татарлыгы белән саклый ала аны. Мин сатира театрын Буада гына калдырмаска, аны менә монда Казанда булдырырга теләр идем. Сатира театры булырга тиеш бит инде Татарстанда. Иң көр күңелле халык бит без!

Алмаз ХӘМЗИН:
– Без, Камил, үзебез язган әсәрләрне укып, хәләл хезмәт белән тамак туйдырдык. Ә хәзер каяндыр ишеткән анекдот белән туйдыралар.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Ә менә бу очракта мин сезнең белән бөтенләй килешмим. Без оештыра торган проектларның барысында да каяндыр анекдот алып, кемнеңдер чыгышларын кабатлап сөйләү тыела. Әле аның анекдотлары бүгенге заманга туры килсә, шатланып тыңлар идең. Бүгенге заман мәзәге актуаль булырга тиеш. Чөнки хәзер тамашачының сайлау мөмкинлеге зур. Америка, урыс, казах юморы арасында синеке дә истә калырга тиеш. Таләпләр зур, анекдотлар белән генә булмый.

Татарча юмор татарчамы?

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Бүген балаларның татар телен аңлауда ихтыяҗы юк, ул аларга кирәкми, чөнки ул алар өчен түгел кебек. Әсәр укыйсың – ул катлаулы телдә язылган. Аны бала ничек аңласын? Телне бөтенләй онытмасын дисәк, бераз заманга җайлашырга, заманча сүзләр кыстырып сөйләшергә кирәк. Шулай булмаганда, аны кем тыңласын соң?

Ә бит яшьләрдә юмор аша телгә кызыксыну уятып була. Юлын гына табарга кирәк. Мәсәлән, мин мәктәп укучылары катнашында бер канал булдырып, анда атнага бер, атнага ике мәртәбә вайннар, ягъни кыска юмористик видеоларга конкурс оештыра идем. Җиңүчеләргә үз кесәмнән чыгарып яки иганәчеләр табып, бераз акча бүләк итә идем. Бу канал конкурс уздыру мәйданы гына түгел, алар өчен аралашу урынына әйләнде. Татарстанның төрле районнарында яшәүче балалар татарча вайннар төшерә, үзара татарча сөйләшә – күңелгә рәхәт бит! Мин бу идеяне әле беркемгә тәкъдим итмәдем, үзем эшлим, әмма ярдәм булса, каршы килмәс идем. Нәтиҗәсе бар чөнки.

Данил СӘФӘРОВ:

– Миңа калса, безгә юморны тарату мәйданнары буенча бүләргә кирәк. Сез юмор турында сөйләшә башлауга, «Чаян» журналы турында әйттегез. Әйе, заманында аның тиражы миллионга якын булган. Ул вакыт өчен ул шаккаткыч мәйдан булган. Бүген аның тиражы меңме, ике меңме? Яшьләр аны укымый да. Сез 20–25 яшьлек егетнең газета тотып утырганын күз алдына китерәсезме? Монысы – аерым. Сатира театрлары – аерым. Интернет – шулай ук үзе бер аерым, зур мәйдан. Егетләр эшли торган Stand Up һәм КВНның яңа юнәлеше – үзе бер мәйдан. Бу – беренчедән.

Икенчедән, бүген яшьләр арасында татар теле проблемасы бар. Юмор җиңелчә генә барырга тиеш. Ә монда, русча фикерләп, татарчага тәрҗемә итеп сөйләшеп... Юморга юл һаман озыная.

Өченчедән, безгә Көнбатыштан Stand Up жанры килеп керде. Ул кешенең үз тормышы турында сөйләвеннән, үз-үзеннән көлүеннән гыйбарәт. Димәк, аудитория үзен танырга тиеш. Ә без кайвакыт үзебезне танымыйбыз. Сезнең бу үзара бәхәсләшү, «сугышу»ыгыз бик кызык ул үзе. Бу очракта мин уртада калганмын. Бу як белән дә, бу як белән дә танышмын. Мин өлкәннәргә яшьләргә карата бераз ачыграк булуны теләр идем.

Рамил АГДЕЕВ:
– Минем татар телем мактанырлык түгел. Җиде ел элек мин татарча бөтенләй сөйләшә белми идем. Ләкин Фәридә Таштабанова (татар КВН лигасына нигез салучы. – **Авт.**), оештыру сәләтемне күреп, татар КВН лигасын миңа тапшырды. Без КВНны башта – Казанга, аннан ТНВга күчердек. Миңа калса бу – зур эш.

Тел мәсьәләсендә мин сезнең белән килешәм. Дөрес, бездә татарча камил белә, яхшы сөйләшә торган комиклар бар. Без дә тырышабыз. Эчтәлеккә кагылышлы тәнкыйтьне дә кире какмыйм. Әйдәгез, алайса, уртак проект ясыйк? Сез авторлар булырсыз. Мин моны татар теле, татар юморы өчен борчылганга күрә тәкъдим итәм.

Камил КӘРИМОВ:
– Бездә юмор-сатира әсәрләренә конкурс та игълан ителгәне юк бугай. Проза, драматургия жанрларына бар, нәтиҗәсе дә күренә. Бәлки, шундый конкурс кирәктер? Әйбәт кенә түләп...

Юмор бир(мә)гән тәрбия турында

Алмаз ХӘМЗИН:
– Яшьләрне игътибар белән тыңлап утырам. Бәлки, алар безне аңламас инде. Әмма безнең бурыч – яраклашу, башкаларга ошаган әйбер бирү түгел, тәрбияләү дә.

Данил СӘФӘРОВ:
– Сөйләшкәндә бу мәсьәләне бердәм әйбергә туры китерү омтылышы бар. Миңа калса, юморның сегментларга бүленеше булырга тиеш. Бу юморны аңлаган кеше монысын аңламаска мөмкин һәм киресенчә. Бу – нормаль күренеш. Яшьләр, олылар, шәһәр кешесе, авыл кешесе, бае, ярлысы – һәм башка билгеләр буенча да аерылырга тиеш. Сез юмор турында сөйләгәндә һаман тәрбия дисез, ә яшьләр юморга андый максат куймый.

Төп проблемалар турында

Данил СӘФӘРОВ:
– Юморның яхшылыгының бер билгесе – аның коммерция ягыннан уңышлы булуы. Әйтик, «Мунча ташы»на кеше билет сатып алып йөри, ул – бу яктан проект. Сезнең проектларны да ТНВ, ялварып, үз мәйданнарында урнаштырырга сораса, шулай ук бу яктан уңышлы дип бәяләргә булыр иде.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Ә нишләп ТНВ сатып алмый соң? Идеяләребез күп, без аларны чынга ашырырга да әзер.

Камил КӘРИМОВ:
– Без совет заманында бушлай эшләдек. Рәхмәт тә әйтүче юк иде.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Ул заман үтте.

Камил КӘРИМОВ:
– Авторлар да югалып бетте.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Ә нигә югалып бетте соң? Чөнки кешенең психологиясе менә ничек эшли: әгәр ул ашау, эчү, яшәү мәсьәләләрен каплый алмый икән, ул аның белән шөгыльләнми.

Алмаз ХӘМЗИН:
– Акчасыз булмый, әйе. Менә, Рамил, сезнең проектны һәрвакыт күрсәтерләр ул. Аларга эфир вакытын тутырырга кирәк. Мин заманында: «Әгәр без хәзер өлкәннәргә – 30, урта буынга – 30, яшьләргә 40 процент урын бирмәсәк, бу безнең татар җырларына балта чабуга тиң булачак», – дип язган идем. Шулай булды да. Хәзер дә вазгыять шундый.

Данил СӘФӘРОВ:
– Тагын аудитория ягыннан чиклелек бар. Әйтик, берәр рус телендә чыгыш ясаучы кеше татарлар турында шаярта икән, аны фәлән мең кеше карарга мөмкин.

Камил КӘРИМОВ:
– Ләкин авторлар базасы булдырмыйча, алга китә алмаячакбыз.

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Ул авторлар базасы белән нишлик соң? Бар ул. Аларның иҗат җимешләрен тарату мәсьәләсе кискенрәк тора.

Камил КӘРИМОВ:
– Сезнең авторлар татар теленең ничә хәрефе белән сөйләшә ала соң?

Фаил БАЯЗИТОВ:
– Аллага шөкер, бер дигән сөйләшәбез.

Камил КӘРИМОВ:
– Бәхәсләшмим. Ләкин шушымыни соң инде авторлар?

Данил СӘФӘРОВ:
– Алар бит 14 яшьтән алып, 25–30 яшьлек аудиториягә эшли. Ә ул аудитория бетеп бара. Хәзер авылдагы балалар да татарча сөйләшми. Бик аз районнарда гына үсмерләр үзара татарча аралаша. Алар ул аудиторияне каян эзләп тапсын соң?

Рамил АГДЕЕВ:
– Җыела ул әкренләп. Шул ук бүген аеруча актуаль булган кыска видеоларны бик күп карыйлар. Техник яктан да, эчтәлек ягыннан да сыйфаты яхшы булса, аны кеше карый.

Алмаз ХӘМЗИН:
– Бу теманың кузгатылуы бик яхшы. Егетләр, эшләргә кирәк. Фикерләрегез нинди булса да, кабул итәбез. «Болай эшлик, тегеләй эшлик» түгел, ә эшләргә кирәк. Сез дә, без дә эшләмәсәк, кем эшләр аны?

Лилия ГЫЙМАЗОВА.
Фото – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

(ХИКӘЯ)

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

ОНЫК

Хәмитнең башка милләт кызына өйләнергә теләгәнен бигрәк тә әнисе Зәрлимә «ярхәмбикалла» дип кенә кабул итмәде. «Шулай инде, үзебезнекеләр санаулы гына булгач, табуы кыен булгандыр», – дип төрттереп әйткәнен иреннән башка беркем ишетмәсә дә, туй көнен билгеләгәннән бирле икенче кешегә әйләнде дә куйды. Аңардагы бу үзгәрешне хәтта песиләре Васька да сизми калмады. Кая инде элеккечә тәмле итеп мырылдаулар да сырпаланулар?! «Аяк астында буталып йөрмә әле!»дән башканы ишеткәне юк хәзер. Исемен дә онытты хуҗабикәсе, «монау хайван» дип кенә җиффәрә башлады. Ә бит ничә еллар «Васькау» дип кенә торганга күнеккән колакларга башкасы бер дә ягымлы яңгырамый. «Аннан килеп, эш исемгә генә кайтып калса, аны бит ул кушмаган! Миңа димәгә, бөтенләе белән булмаса да, мыегымны да селкетмим! Ә бит үзләренең ничә еллык гаилә дусларының исеме дә – Василий. Клава түти белән әле кичә генә килеп киттеләр. Күгәрченнәр кебек гөрләштеләр, серләштеләр. «Василий кордаш» дип кенә тордылар. Аңламассың! Менә шундый уйлар биләп алды әле Васьканы да бу көннәрдә.

Гаделҗан абзый исә, хатыны тагын да ныграк кабынып китмәсен өчен, артык сүз кыстырмады. Бәй, хәзер аңардан да уздырып, тискәрегә сөйли башласаң, туйга нокта куярга гына калачак. «Баланың сайлаган кешесенә ничек каршы киләсең инде? – дигәнрәк фикер йөртте Гаделҗан абзый. – Димәк, ярата. Ә яратудан да көчлерәк хис бармы соң?» Үзләренә ике йорт аша яшәгән авылдашларының кызлары удмурт егетенә кияүгә чыкканын да уйлап куйды. Менә дигән яшәп яталар ич. Кода-кодагыйлары да еш кунакка килә, үзләре дә атлаган саен барып кына торалар. Кияү авылга кайтса, шартлатып татарча сөйләшә, кызлары да аларның телен су кебек эчә, имеш. Мәгәр бу якта оныкларының әби-бабайлары белән башка телдә сөйләшкәннәрен ишеткәнем юк. Аның каравы әнә өлкән абыйсының балалары чеп-чи татарлар белән кушылганнар иде дә, оныклары, ичмасам, бер генә җөмлә дә үзебезчә оештырып әйтә белмиләр.

Гаделҗан абзый белән Зәрлимә апа уллары Хәмиттән моңа кадәр бик разый булдылар. Мәктәптә яхшы укыды, йөзләренә кызыллык китермәде. Студент елларында да гел авылга кайтып ярдәмләшеп йөрде. Диплом алганнан соң, төзелеш өлкәсендә эшләү дәверендә дә әти-әнисенә, апа-сеңелләренә гел терәк булып торды.

Әлбәттә, Хәмит үзенең туен да әти-әнисенең җилкәсенә салмаячагын белә иде Гаделҗан абый белән Зәрлимә апа. Хәер, үзләре дә хәзер матур, тук, нык тормышта яшәгәнгә, ул яктан артыгын көяләнмәделәр. Туйны Мәскәүдә үткәрергә килешенде. Бөтен эчне кырганы – килен тиешле кешенең башка милләттән булуы.

«Рәхәтләнеп, бердәнбер киленең белән үз телеңдә сөйләшмәгәч, ни кызыгы инде бу дөньяның?» – дип, тагын сүз кузгатты кичке аш вакытында Зәрлимә апа. Гадәттәгечә Гаделҗан абзый тыңлап кына утырды. «Ярый, йорт-куранының бер җирендә дә тотынмыйбыз, менә дигән әле, ашарга сорамый, торсын шулай», – дип йомгаклап куйды сүзен Зәрлимә апа. Ә бит яңарак кына планнар икенчерәк иде. Яз көне Хәмит: «Яңа еллар тирәсенә өйләнергә уйлыйм», – дигәч, җиләк-җимешләр әзерләү чоры үтүгә ныклап ремонтка тотынырга исәп тотып торалар иде. Кияүгә китмәгән ике кызлары да булгач, комачау итмәс, дип уйлашты алар ул чакта. Яшьләре җиткән, бүгеннән генә кияүгә чыгам, димәсәләр дә, көннәре якынайганын сизенәләр иде Гаделҗан абзый белән Зәрлимә апа. Инде эшне башларга гына торганда: «Бер айдан – туй», – дигән хәбәр җибәрде уллары. Балага каршы килеп буламыни? Яңарту көтеп торган йорт-кура мәсьәләсе үзеннән-үзе хәл ителде дә куйды. Юк, әгәр дә уллары сайлаган кыз үзебезнең милләттән булса, һич югы башкадан булып та, якын-тирәләрендә яшәгән булса да, риза булыр идең әле. Нәрсә диләр әле? Үзеңнеке – үз, сукыр булса да, күз! Юк, җир читендә – Сахалинда туып-үскән булып чыкты булачак киленнәре! Гаделҗан әйтә ул: «Сахалин борын төбендә генә», – дип. Булды ди! Аңа ни, шунда хезмәт иткәч, якын инде, бер дә ерак кебек түгел. Гомер буе гаилә дуслары арасында башка милләт кешеләре булса да, нигәдер баланың үз татарың белән кушылмавы күңелгә бик хуш түгел икән ул. «Разведчикка укыган диярсең, нинди кыз белән дуслашып йөрүеңнең җөен дә белдермәде ичмасам!» – дип, Зәрлимә апа савыт-саба юганда да тынычлана алмады. Гаделҗан абзый бу юлы баш кагып булса да алды.

Туйга чак кына вакыт калса да, Зәрлимә апа әзерлек эшләрен тартты да сузды. Ялга кайткан кызлары да: «Әнкәй, синеңчә түгел әле бу, гадәттә бер ай алдан итәк-җиңеңне җыеп куя торган идең», – диештеләр. Аннан көйләп-чөйләп дигәндәй, туйга киеп барасы киемнәрен әзерләп, күчтәнәчбүләкләрен төйнәшеп, оештырып киттеләр. Җиләк-җимешкә бай, бөрлек бераз басылган август аенда яшьләрнең никахлары теркәлде. Туй мәҗлесе артык шау-шулы узмады, ике яктан да иң якын кешеләр генә чакырулы иде. Бер ай тирәсе узгач, төп йортта килен төшерү, су юлы күрсәтү йолаларын уздырдылар, кичен агайэне, дус-ишне табынга җыйдылар.

Ахыры бар >



Сканворд җаваплары

Горизонталь: чеби, Ачасыр, Ишимбай, ала, Ершов, биана, рейс, әби, ТИ, сатлыкҗан, Булат, ак, имин, Әлфәт, зар, ураза, дорфа, Айн, уй, Закирова, уку, ишек, биреш, әтәч, әле, халык, мат, ру, варис, бүрәнә, Раилә, уч, тот, им, Маликов, Гагарин, ым, ватык, Әнәс, ярканат, Ка, Иван, Ли, Ми, әйдаман, ля, Яратам, анализ, нота.

Вертикаль: чигә, Зәбәер, Игәнәй, еш, балта, ил, урман, Биби, керем, гәүдә, ими, бәби, Адидас, батут, Ришат, иму, Данил, до, Вәлиева, йә, Азов, ана, Стара, рам, Ян, чара, РФ, Ла, Алет, ау, сулык, ял, сайлау, чимал, сыкрау, Нияз, ре, ай, Мәхмүтова, җизни, та, ватман, ашлама, Әлмәт, Ито, ни, уенчы, нотык, ат, ява, Найк, куәт, капма.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Әз-мәз мәзәк



– Яз көне минем тәрәзә астында мәчеләр концерт куя.
– Матурмы?
– Юк. Арзанлы попса.

***

– Сезнең авылда клуб эшлиме?
– Элек эшли иде. Әмма алар анда гел сугышты, тәртипсезләнде, шуңа күрә яптылар.
– Кем ул «алар»?
– Без инде.

***

Кайчандыр мин официант булып 40 мең сум эшли идем. Белем алмый булмас дип, шәфкать туташына укып чыктым. Хәзер хезмәт хакым – 20 мең сум.

***

– Син мине аңлыйсыңмы?
– Аңлыйм.
– Миңа да аңлат әле.

***

– Исәнмесез! Сезнең фатирдан инде ике көн эт улаган тавыш ишетелә.
– Эт түгел ул. Мин имтиханга әзерләнәм.

***

– Ох! Шундый рәхәт, яшиселәр килеп китте, тормышка яңача карый башладым.
– Гашыйк булдың мәллә?
– Юк, хезмәт хакы бирделәр.

***

– Ачу чыкканда бераер физик эш эшләргә кирәк, диләр.
– Нинди, мәсәлән?
– Мин тәрәзәләр юа башлыйм. Автобуста барган кешеләр аптырап кала хәтта.

Беләсең килсә...

1 Кайсы театр Тукай исемен йөртә?
а) Түбән Кама театры;
б) Чаллы театры;
в) Әтнә театры.

2 «Бишенче республика» дип кайсы илне атыйлар?
а) Польша;
б) Франция;
в) Австрия.

3 Боларның кайсы кактус түгел?
а) трихоцереус;
б) ребуция;
в) брианит.

4 Композитор Эльмир Низамов кайда туган?
а) Пензада;
б) Сембердә;
в) Ижауда.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. в); 4. б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 236

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**. 16+